Научно-практический журнал

# БИБЛИОТЕЧНЫЙ ВЕСТНИК

2 (48) 2019

# КИТАПХАНӘ ХӘБӘРЛӘРЕ

Фәнни-гамәли журнал












*Арча Җиңү паркында* | *В Парке Победы Арска*



*Якташларыбыз – Советлар Союзы Геройлары аллеясы* | *Аллея земляков – Героев Советского Союза*

БУ САНДА:
В НОМЕРЕ:


**Татарстан китапханәләре: Арча ● Библиотеки Татарстана: Арск**
*А. Мухаметшина.* Арская ЦБС – на пути активного развития ................. 2
***Алар Арча китапханәләрендә эшли ● Библиотеки Арска в лицах***
*А. Зәкәрова.* Китапханә тарихын тудыручылар ........................................ 8
*Ә. Галимова.* «Илһам – күңел канаты» ...................................................... 10
*И. Хәнәфиева.* Ихтирамга лаеклы шәхес .................................................. 12
**Иҗади очрашулар ● Творческие встречи**
*С. Гәрәев.* Бөек шагыйрь җирлегендә ........................................................ 14
**Әдәби сәхифә ● Литературная страница**
*Г. Тукай, М. Ногман, С. Әхмәтҗанова, Н. Касыйм, Р. Җамал, М. Шәрәпов, Г. Шәрипова, Н. Йосыпова* ................................................... 18
**Эш тәҗрибәсе ● Опыт работы**
*А. Зәкәрова.* «Ак калфак» – халкым нуры .................................................. 20
*Г. Камалова.* Будущее – это мы ................................................................. 23
*Л. Капралова.* Изучая – сохраняем ........................................................... 25
*А. Рахимбаева.* Творим добро сегодня
Особенности работы с детьми-инвалидами ............................................ 27
*Р. Хакимова.* Информационные технологии в условиях
современной библиотеки ............................................................................ 29
*Г. Хасанова.* Традиции и новации в работе отдела комплектования ........ 31
***Сельские библиотеки Арского района***
*Р. Әүхәдиева.* Тормыш яме – яшәүдә, яшәү яме – гаиләдә ....................... 33
*Н. Әхмәтҗанова.* Без – Тукайлы халык ...................................................... 34
*Г. Ибраһимова.* Хәтерләүдән курыкма син, үткәнеңне онытма син! ...... 36
*Н. Йосыпова.* Авылым күрке – китапханә ................................................. 38
**Республика китапханәләрендә ● В библиотеках республики**
*И. Боготолова.* Уезжаем, чтобы возвратиться ............................................ 40
*Л. Сабирова.* В гостях у коллег ................................................................... 42
*Ф. Рәхимова.* Истәлекле очрашу ................................................................. 45
*Э. Мәгалимова.* Яшь иҗатчылар – китапханә кунаклары ......................... 46
**Истәлекле даталар ● Знаменательные даты**
*М. Липачева.* Театр – в книгах, газетах, афишах ....................................... 48
*Р. Ахмадиева.* Полвека служения культуре:
Казанскому государственному институту культуры – 50 лет .................. 54
*А. Абдулхакова.* Грант Правительства Республики Татарстан ................. 57
*Г. Кормишина.* Библиотечная школа Республики Татарстан .................... 61
**Чит илләрдәге хезмәттәшләребездә ● У зарубежных коллег**
*Е. Сокур.* Взаимодействие в украинской библиотечной науке. ............... 65
**Якутлар табыладыр вакыт белән ● Наследие**
*И. Һадиев.* «Тажетдин Ялчыгол» китабы ..................................................... 68
*Ф. Гарипова.* Шәхесләребез белән бизәлә туган авылыбыз тарихы ......... 72
*О. Иванова.* Великие библиотекари: Иван Крылов .................................. 74
*Г. Хөсәенова.* Татар журналисты Шәриф Байчура ..................................... 78
***Татарстан китапханәләре хакында вакытлы матбугат ● О библиотеках Татарстана в периодической печати*** ............................ 81
***Вакыт-вакыйга ● Хроника***
*Р. Миңнеханов.* Без китапка кире кайтачакбыз ........................................... 89
Экспозиция разных эпох .............................................................................. 90
*Иса Габиббейли.* Поэтические мосты дружбы ............................................ 91
В Китае открыли книжный магазин с бесконечными полками ................ 94
Татарстанның Чирмешән һәм Аксубай районнары
Үзәк китапханәләренә 100 ел ....................................................................... 95


● **Тышлык битләрендә:** Арча районы һәм шәһәре күренешләре. Ленар Гобәйдуллин фотолары.
● **На страницах обложки:** Виды Арского района и города Арска. Фото Ленара Губайдуллина.


# КИТАПХАНӘ ХӘБӘРЛӘРЕ

№ 2 (48) 2019

ФӘННИ-ГАМӘЛИ ЖУРНАЛ

Татарстан Республикасы Милли китапханәсе тарафыннан 1996 елның май аеннан башлап нәшер ителә. Елга 2 тапкыр татар һәм рус телләрендә чыгарыла.



Баш мөхәррир
Р. И. Вәлиев

Редколлегия:
С. Р. Җиһаншина,
И. Г. Һадиев, Ә. Х. Мушинский
*(баш мөхәррир урынбасарлары),*
Р. Ә. Хөсәенова
*(җаваплы сәркятиб),*
А. Р. Габделхакова,
А. Җ. Заһидуллин



# БИБЛИОТЕЧНЫЙ ВЕСТНИК

№ 2 (48) 2019

НАУЧНО-ПРАКТИЧЕСКИЙ ЖУРНАЛ

Издается Национальной библиотекой Республики Татарстан с мая 1996 года. Выходит 2 раза в год на татарском и русском языках.



Главный редактор
Р. И. Валеев

Редколлегия:
С. Р. Зиганшина,
И. Г. Хадиев, А. Х. Мушинский
*(заместители главного редактора),*
Р. А. Хусаинова
*(ответ. секретарь),*
А. Р. Абдулхакова,
А. З. Загидуллин

*Алина МУХАМЕТШИНА,*
*директор муниципального бюджетного учреждения*
*«Арская централизованная библиотечная система»*



*Эта сторона лесная вечно в памяти жива.*
*Бархатистым одеялом расстилается трава.*
*Там ни холода, ни зноя никогда не знал народ:*
*В свой черед подует ветер, в свой черед и дождь пойдет.*
Габдулла Тукай

# Арская ЦБС – на пути активного развития

АРСКИЙ муниципальный район – один из крупнейших районов Республики Татарстан, расположенный в центре северной части западного Предкамья – образован в 1930 году. Административный центр – город Арск возник в начале XIII века как северо-западный форпост булгаро-татарского государства. Его история представляет собой процесс развития поселения, основанного булгарами в тесном взаимодействии с народами Предкамья, объединившимися в рамках государственных традиций Волжской Болгарии, Казанского ханства, а позднее – и Русского царства.



*Библиотека в наши дни*

На сегодняшний день в районе проживают более 50 000 человек, из них 92,1 процент – татары, остальные – русские и представители других национальностей.

Арский район – один из передовых сельскохозяйственных районов Татарстана: здесь развито мясо-молочное и зерновое направления. В районе действуют предприятия легкой промышленности, предприятия по обслуживанию сельского хозяйства, хранению и переработке сельскохозяйственной продукции, а также строительные организации.

Передовые позиции занимает Арск и по уровню здравоохранения, образования, культуры и спорта.



*Экскурсия по библиотеке Министра культуры РТ И. Х. Аюповой*



*Практикум для сельских библиотекарей*

Арский край исторически известен как центр национальной культуры. Его жители по праву гордятся своими великими земляками – просветителями, выдающимися писателями, деятелями искусства, учеными, такими как Габденнасыр Курсави, Шамсетдин Культеси, Шигабутдин Марджани, Галиасгар Камал, Махмут Галяу, Габдулла Тукай.

Библиотеки Арского района занимают заметное место в культурном пространстве города и села. Арская централизованная библиотечная система – одна из крупнейших в республике, в неё входят 57 библиотек: 7 городских и 50 сельских, в том числе две детские – в городе и на селе.

Базовым элементом ЦБС является ее фонд, состоящий из более 470 000 экземпляров документов: книг, периодических, аудиовизуальных и электронных изданий. Книгообеспеченность на одного жителя составляет 9 книг, на одного читателя – 12 книг.

С февраля 2017 года осуществляется выдача единого читательского билета (ЕЧБ), при этом сохраняется традиционный формуляр читателя.

Развитие библиотечного дела в крае неразрывно связано с историей страны, республики, района. Первые библиотеки в Арском районе появились еще до революции. Позже их объединили в избы-читальни. Книг в них было мало, поэтому кто-то читал вслух, кто-то – слушал. Здесь проводились беседы, обсуждались события в мире, новости и новые книги. Позже библиотека стала получать газеты и журналы, появились настольные игры, шашки, шахматы… Так как ликвидация неграмотности и просветительская работа были возложены на учреждения образования, избы-читальни были отнесены к районному отделу образования.

Арская районная библиотека открылась в 1934 году. В те годы она располагалась в доме № 2 на Советской площади. Библиотека проводила большую работу по просвещению населения, повышению уровня знаний. В 1939 году был составлен договор с колхозами об использовании книг из Арской библиотеки. Именно тогда в Арске начали свою работу выездные библиотеки. Библиотекари выезжали на производство и вели пропагандистскую работу, о чем регулярно сообщалось в районной газете «Новая жизнь».

В годы войны перед районной библиотекой была поставлена важная задача – патриотическое воспитание граждан. Для решения этой задачи был использован весь арсенал русской и советской литературы. Читатели собирались в библиотеке, следили за известиями с фронта.



*У каждой свой выбор*



*Пополняем знания*



*«Прикоснись ко мне добротой» (беседа со школьниками)*

На 16-й сессии Арского районного Совета депутатов трудящихся, которая состоялась 15 декабря 1944 года, на работников библиотеки были возложены новые обязанности: «...подобрать из числа актива, в первую очередь из учителей, наиболее подготовленных для работы в качестве избачей, улучшить работу изб-читален. Завезти топливо, приобрести для изб-читален художественную и политическую литературу, проводить коллективные радиослушания, вечера самодеятельности, организовать кружки агротехучебы, выпуск стенных газет».

В 50-е годы в селах Арского района было открыто большое число библиотек.

В соответствии с Положением Министерства культуры РТ в 1974 году Арский районный исполнительный комитет принял Постановление о цент-рализации государственных библиотек. Централизация была проведена в целях полного удовлетворения потребностей читателей в книгах. 72 сельские библиотеки района (включая Атнинский район) стали сельскими филиалами, а районная библиотека стала именоваться Центральной.

В 1981 году Арская центральная библиотека одной из первых в республике переехала в новое здание, построенное по специальному типовому проекту. В строительство библиотеки и успешное выполнение работ по централизации внесла большой вклад ее первый директор Аниса Маннапова.

Арская централизованная библиотечная система по итогам 1983 года заняла первое место среди районов республики и удостоилась переходящего Красного Знамени Совета Министров РСФСР. Высокие результаты во многом были достигнуты благодаря эффективному руководству библиотекой. В разные годы ее возглавляли Ринат Шадалеевич Гадельшин, Любовь Михайловна Осина, Лилия Рафиковна Фазылова.



*Выставка детского творчества*

И сегодня библиотеки остаются центрами интеллектуальной и культурной жизни района. В библиотечной системе трудятся 78 работников – люди творческие, бесконечно преданные избранному делу. Изо дня в день они делают своё дело, на первый взгляд, неприметное, но требующее собранности, эрудиции, отзывчивости и чувства такта в общении с читателями.

Заведующая отделом обслуживания Центральной библиотеки Альфия Накиповна Галимова, заведующая Новокишитским сельским филиалом Надия Ризвановна Юсупова являются заслуженными работниками культуры РТ. Алсу Миннахметовна Закарова, Алсу Гарифзяновна Рахимбаева удостоены Гранта Правительства Республики Татарстан для поддержки лучших работников учреждений культуры, искусства и кинематографии в номинации «Профессионал».

МБУ «Арская ЦБС» ведет свою работу по различным направлениям: работа с детской, молодежной аудиторией; изучение родного края, воспитание бережного отношения к окружающей среде; семейное, нравственное и эстетическое воспитание; пропаганда здорового образа жизни; организация полез-



*Литературный лингвовечер*



*Гостья библиотеки писательница А. Ахметгалиева со старшим методистом А. Галимовой*

ного досуга для пожилых, людей с ограниченными возможностями здоровья и т. д.

Библиотечное обслуживание населения осуществляется в координации с учреждениями образования и культуры, общественными организациями, средствами массовой информации. Ведется тесное сотрудничество с Арским педагогическим колледжем, Арским гуманитарно-техническим техникумом, общеобразовательными учреждениями района. Совместно с дошкольными учреждениями вот уже второй год проводятся городские конкурсы на знание родной литературы и традиций татарского народа.

Хочется отметить активное участие библиотеки в международной акции «Наши истоки. Читаем фольклор», в республиканской – «Время читать самое лучшее: читаем книги лауреатов премии им. А. Алиша», в конкурсах «С именем писателя-земляка край родной прославляю», «Джалиловские чтения», в районном конкурсе чтецов «Огонь поэзии в наших сердцах».

Большое внимание в ЦБС уделяется краеведческой деятельности, в том числе пропаганде творчества писателей и других деятелей искусства края. Были разработаны персональные папки, посвященные жизни и творчеству великих татарских писателей-земляков Г.Тукая, Г.Ахунова, Г.Баширова, М.Магдиева.

За последние годы собрано много информации об истории района, его выдающихся личностях, изданы книги: «Бөек Тукай Ватаны син, Арча» (2009), Р.Г.Галлям, К.Ф.Фасхутдинов «Город Арск: история и современность» (2012), Р.А.Юсупов и другие «Есть деревня за Казанью – величается Кышкар» (2014), Р.Фазлиахметов «История в лицах. Арский район 1920–2017» (2017), «Арча ягы шаярулары» (2018), «Арча ягы – данлы төбәк» (2019) и др.

Библиотекари активно пропагандируют творчество местных литераторов. Огромную работу по выявлению и поддержке новых талантов проводит литературное объединение «Каурый каләм» при Центральной библиотеке. За последние годы восемь наших авторов выпустили сборники своих произведений. В библиотеке проводятся презентации изданий, встречи учащихся с местными писателями.

С 2016 года во всех библиотеках района стартовали литературные площадки «Әдәби мәйдан». Празднование 130-летия со дня рождения великого татарского поэта Г. Тукая состоялось в театре им. К. Тинчурина при активном участии Арского землячества.

Заслуживают внимания и результаты деятельности краеведческих клубов. Необходимо отметить работу клуба «Кайтаваз» при Кышкарской сельской библиотеке. Никого не оставило равнодушным мероприятие «Кышкарга – 400 яшь», проведенное совместно с сельским клубом. Библиотека подготовила выставку-исследование, на которой представила обширную информацию о земляках, знаменитых деятелях – выпускниках Кышкарского медресе, среди которых были известные ученые, писатели и государственные деятели. Результатом активной поисковой деятельности стала книга «Есть деревня за Казанью – величается Кышкар». В текущем году ее составитель Рузаль Абдуллазянович Юсупов был награжден Почетной грамотой Российской библиотечной ассоциации «За вклад в развитие библиотечного краеведения России».



*Обсуждение вопросов в методическом отделе*

В 2019 году в Центральной библиотеке состоялась литературная встреча «Китап язмышы – халык язмышы» («Судьба книги – судьба народа»), посвященная 100-летию Татарского книжного издательства. На встречу с любителями литературы были приглашены представители Союза писателей Татарстана Ленар Шаех, Галимзян Гильманов, Эльмира Шарифуллина.

Пристальное внимание библиотеки Арского района уделяют проблеме экологии. Библиотеки района занимаются экологическим просвещением населения, привлекают читателей к литературе, раскрывающей различные аспекты экологических проблем. В целях формирования экологической культуры проводятся массовые мероприятия – акции по посадке деревьев, чистке озер, родников, лесных зон, изготовлению кормушек. Нельзя не отметить экологический проект «Сдай батарейку, спаси ежику жизнь», в результате которого в добрые руки экологов были переданы более 350 кг батареек, собранные со всего района. После этой акции в библиотеке были зарегистрированы 68 новых пользователей.

С июля по сентябрь текущего года был проведен экологический конкурс «Волшебные превращения», в ходе которого участниками были представлены костюмы литературных героев, выполненные из бросового материала. В рамках конкурса состоялось торжественное мероприятие «От чистого города – к зеленой планете» при участии представителей Министерства экологии РТ.

В библиотеках района систематически проводятся встречи с представителями литературы и искусства. Изменилась и форма проведения многих мероприятий, что сделало их более содержательными. Каждое событие и книжная выставка сопровождаются электронной презентацией. Особое внимание уделяется созданию буктрейлеров. Это самый верный способ подать информацию зрелищно, необычно. В связи с расширением социальных сетей в работу начали включаться интернет-проекты: в текущем году были организованы акции #Китаплыфото, #БезТукайныукыйбыз, в которых приняли участие более 500 человек.

Библиотеки района уделяют большое внимание работе с инвалидами и пожилыми людьми. Налажено тесное сотрудничество с Реабилитационным центром для детей и подростков с ограниченными возможностями здоровья Министерства труда, занятости и социальной защиты РТ «Исток надежды» в Арском муниципальном районе, с Арским домом-интернатом для престарелых и инвалидов. На их базе проводятся выездные встречи, реализуются литературные программы, ведется библиотечное обслуживание. В текущем году Арская ЦБС с проектом «Старость в радость» стала победителем конкурса грантов Президента РФ по организации досуга пожилых людей.

В Центральной библиотеке работает кабинет для слепых и слабовидящих, где предоставляется специальная литература на дисках, кассетах, флешкартах и книги шрифтом Брайля. Литература по запросам инвалидов ежеквартально обновляется через Республиканскую библиотеку для слепых и слабовидящих РТ.

Совершенствование деятельности библиотек, внедрение инновационных форм и методов работы, повышение квалификации библиотечных работников – непременные составляющие методической деятельности МБУ «Арская ЦБС». Для сотрудников проводятся семинарские занятия, деловые игры, круглые и дискуссионные столы, дни творческих идей, индивидуальные консультации.

В октябре 2018 года в рамках XI Всероссийской научно-практической конференции «Библиотечные фонды: проблемы и решения» на базе Центральной библиотеки состоялось выездное заседание на тему «Новые подходы к формированию фондов муниципальных библиотек». Более 200 участников конференции из различных регионов России познакомились с работой Центральной и Районной детской библиотек.



*Выбор книги*



*Литературные игры*



Презентация книжной выставки



На профилактическом уроке

В апреле 2019 года совместно с Туймазинской ЦБС Республики Башкортостан был проведен межрегиональный семинар «Развитие инновационных форм деятельности библиотек: проблемы и пути решения». Было принято решение о межрегиональном сотрудничестве.

Известно, что динамичное развитие любой организации, ее положительный имидж, уверенность в будущем не происходят сами по себе. Все это требует постоянных последовательных усилий: поддержки активной инновационной стратегии, развития системы управления проектами, инициативы и предприимчивости. МБУ «Арская ЦБС» активно занимается проектной деятельностью. Ежегодно сельские филиалы становятся обладателями республиканского гранта «Лучшее учреждение культуры, находящееся в сельской местности». С 2010 года данный грант получили восемь сельских библиотек. В этом году грант получила Ашитбашская сельская библиотека. Гранты позволяют укрепить материально-техническое состояние библиотек и улучшить качество библиотечного обслуживания.

В 2017 году Районная детская библиотека с творческим проектом «Читальный кинозал» выиграла грант Правительства Республики Татарстан. Создание в библиотеке «Читального кинозала» позволило детям и подросткам приобщиться к классической литературе, познакомиться с произведениями как в оригинале, так и в кинопостановках.

Центральная библиотека в 2019 году стала обладателем гранта на организацию Виртуального концертного зала в рамках федерального проекта «Цифровая культура» национального проекта «Культура». Вместе с популяризацией академической филармонической музыки и созданием равного доступа к культурным ценностям России всех граждан независимо от их места проживания данный проект позволяет расширить круг читательской аудитории и благодаря современному музыкальному оборудованию повысить качество проводимых мероприятий.

В этом году библиотека села Новый Кырлай – родины великого татарского поэта Габдуллы Тукая – стала обладателем федерального гранта в размере 5 млн рублей на модернизацию библиотеки. Мы надеемся, что данная библиотека станет образцовым учреждением культуры Республики Татарстан и центром национального чтения.

Библиотечная система Арского муниципального района держит курс на активное развитие. Мы надеемся, что современная государственная политика в сфере библиотечного дела, профессионализм и заинтересованность самих библиотекарей поднимут статус библиотеки, расширят круг ее пользователей. ■

*Арча – данлыклы Казан артының үзәге. Татар халкының тарихына үзеннән лаеклы өлеш керткән, милләтебезнең этник нигезен ачып салучы, халкыбызның сөйләм һәм әдәби телен саклап калучы як ул! Әлеге төбәкнең күпгасырлык тарихи, мәдәни традицияләре бар. Арча ягы үзенең бөек мәгърифәтчеләре, күренекле язучылары, сәнгать эшлеклеләре, галимнәре, тырыш һәм эш сөючән халкы белән дә данлыклы.*

*Арча районы китапханәләре, гомер-гомергә мәгълүмати, мәдәни үзәкләр буларак, халыкның белемен арттыру, һәрьяктан камил буын тәрбияләү юнәлешендә эшлиләр. Китапханәләр – хәзерге көндә районда иң күренекле, дәрәҗәле, халык теләп йөри торган урыннарның берсе. Яңа заман яңа таләпләр куя – Арча районы китапханәләре, ирешелгән уңышларга таянып, яңа үрләр яуларга әзер.*

*Мәдәният өлкәсендәге дәүләт сәясәте китапханәләргә булышуны дәвам итеп, аларның эшчәнлеген алга җибәрер, китапханәләрнең статусын тагын да югарырак күтәрер, китап укучылар даирәсен киңәйтер дигән ышаныч белдерелә.*

● АЛАР АРЧА КИТАПХАНӘЛӘРЕНДӘ ЭШЛИ
● БИБЛИОТЕКИ АРСКА В ЛИЦАХ

*Алсу ЗӘКӘРОВА,*
*Үзәк китапханәнең*
*методик-библиографик бүлеге мөдире*

# Китапханә тарихын тудыручылар

Һ ӘР китапханәнең үзенә генә хас тарихы бар. Китапханә тарихы, китапханә эшенең уңышлары һәм үсеше анда эшләүче кешеләрдән аерылгысыз. Бу сүзләрнең хаклыгына Арча үзәкләштерелгән китапханәләр системасы тарихы аша тагын бер кат инанасың. Әйе, хәзерге көндә китапханәбезнең республика китапханәләре арасында лаеклы урыны, районыбызда югары дәрәҗәсе, иң мөһиме, китапны, басма сүзне яраткан алыштыргысыз укучылары бар. Боларның барысы өчен дә без китапханәләр тарихы битләренә лаеклы өлешен керткән кабатланмас остазларыбызга бурычлы. Алар арасында райондагы беренче китапханәчеләр Раиса Павлова, Екатерина Барышева, Анна Коркинаны әйтеп үтәргә кирәк. Үзләрен китапханә хезмәтенә багышлаган фидакарь китапханәчеләр – Үзәк китапханәдән Ая Нуриева, Люция Галимова, Фәймә Әминова, авыл китапханәләре арасыннан Сәвия Исмәгыйлова (Күпербаш), Мөршидә Мифтахова (Казанбаш), Мәхмүдә Хәбибуллина (Иске Кырлай), Мөзәвирә Сабирҗанова, Рәмзия Валиуллина, (Яна Кенәр), Мөгалимә Йосыпова (Күлтәс), Әминә Зәкәрова (Югары Пошалым), Флера Әскәрова (Иске Төрнәле), Хәҗәрбикә Мөхәмәтшина (Шушмабаш), Фәймә Заһидуллина (Ашытбаш), Әлфия Рәхимова (Шәһәр китапханәсе), Люба Кузнецованы (Лесхоз) да



Алсу Зәкәрова

атап үтү урынлы булыр. Аларның һәрберсе үзен югары профессиональ хезмәткәр буларак танытты. Китап укучылар күңелендә олы җанлы, якты шәхес, сердәшче һәм киңәшче буларак истә калды.

Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы төзелгән һәм аннан соңгы елларда җитәкчелек иткән Әнисә Маннапова, Ринат Гаделшиннар тирән белемле, иҗади эшләүче коллектив тупладылар. Шулай ук китапханәләрнең матди базасын ныгыту, хезмәткә уңайлы шартлар тудыру җитәкчеләрнең төп бурычлары иде.

Любовь Михайловна Осина китапханә эшенең танылган лидеры булды. Любовь Михайловна җитәкчелегендәге китапханәләр системасы күп еллар дәвамында «Иң яхшы китапханә» исемен йөртте. Нәтиҗәле хезмәте өчен Любовь Михайловнага 2000 елда «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме бирелә. Үзгәртеп корудан соңгы катлаулы елларда директор район китапханәләре челтәрен саклап калырга тырышты, аларның матди хәлен ныгыту белән шөгыльләнде. Любовь Михайловна «Россия китапханәләре өчен Китаплар» программасын күздә тоткан «Пушкин китапханәсе» Мегапроектына керүгә ирешә. Нәтиҗәдә безнең китапханә ташламалы түләү режимы буенча барлык белем тармаклары буенча яңа, иң яхшы басмаларны ала башлады. Җитәкче вазифасы директорга районның сәяси вакыйгаларының үзәгендә булырга, мәдәният һәм китапханә эшенең үсеш процессларына җитди йогынты ясарга мөмкинлек бирә. Любовь Михайловна китапханәнең дәрәҗәсен югары күтәрде, үз тирәсенә иҗади кешеләр командасын туплады, үзенең барлык идеяләрен хезмәттәшләренә җиткерә алды.

Фазылова Лилия Рәфыйковна гомере буе китапханәдә эшләде. Кечкенәдән әнисенә ярдәм итеп, китапханәдә үскән кыз һөнәр сайлау вакыты җиткәч, ике дә уйламыйча, Алабуга мәдәният техникумына укырга китә. Тырыш, белемгә омтылучы кеше буларак, читтән торып Казан мәдәният институтын тәмамлый. Хезмәт юлын гади китапханәче буларак башлап, библиограф, методик бүлек мөдире, соңгы 17 елда Арча Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы директоры булып эшли. Лилия Рәфыйковна җитәкчелегендә




*Үзәк китапханәдә буыннар очрашуы*

коллектив даими рәвештә эшнең яңа формаларын һәм методларын эзләүдә булды. Эшкә җаваплы һәм җитди карады һәм шуны ук хезмәткәрләреннән дә таләп итте. Үз максатларына ирешүдә үҗәтлек күрсәтеп, иң катлаулы проблемаларны ыгы-зыгысыз гына хәл итә белде. Лилия Рәфыйковна җитәкчелек иткән елларда китапханәләренең матди-техник базасы ныгый һәм киңәя, китап фондлары яңартыла. Замана таләпләренә яраклашып, китапханәчеләр яңадан-яңа компьютер программаларын үзләштерәләр. Г.Тукайның тууына 125 ел тулу уңаеннан «Китапханәләргә ярдәмгә» дигән республика программасы нигезендә «Арча Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениясенә 4 млн 450 мең сумлык заманча техника һәм мебель бирелде. Нәтиҗәдә, китапханәләргә укучылар тарту өчен яңа мөмкинлекләр ачылды. Лилия Рәфыйковна Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының һәм Россия мәдәният хезмәткәрләре профсоюзының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Үзәк китапханәдә һәм Район балалар китапханәсендә эш стажлары 20 дән 40 елга кадәр булган китапханәчеләр: Татарстан республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Сирена Сабирова, Мөнирә Акбашева, Мәрьям Кашапова, Нурхөдә Әхмәтовалар турында бары тик җылы сүзләр генә әйтергә була. Алар нәни китап укучыларны әкиятләр, сәяхәтләр белән тулы тылсымлы дөньяга алып керә белделәр. Китапны яратырга өйрәттеләр. Китап геройлары балалар күңеленә кучте. Бүген инде үзләре әти-әни булсалар да, алар балачактагы китапханәчеләрне рәхмәт хисләре белән искә алалар.

Рәйсә Зариф кызы Хәсәнова китапханәче, аннары район китапханәсе методисты булып эшләде. Аның катнашындагы семинарлар һәрвакыт кызыклы һәм бай эчтәлекле узды. Ул һәрвакыт таләпчәнлеге һәм принципиальлеге белән аерылып торды. Авыл китапханәчеләре аны хөрмәтләп, киңәш сорап мөрәҗәгать иттеләр. Рәйсә Зариф кызы зирәк остаз иде.

Вакыт бик тиз үтә... Күп хезмәткәрләр сайлаган һөнәрләренә тугры калдылар, аларның стажы 20, 30 һәм аннан да күбрәк хезмәт еллары белән исәпләнә. Китап туплау һәм эшкәртү бүлеге хезмәткәрләре Зәйнәп Нуриева, Әлфия Сөнгатуллина, Роза Сәләхетдинова, Сания Ганиевалар үз эшләренең остасы булып танылдылар, китап фондының бай булуы, укучыларның барлык сорауларын канәгатьләндерү өчен тырыштылар. Олы хезмәтләре өчен, Зәйнәп Нуриева һәм Сания Ганиева Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек булдылар.

Китапханәгә яшьләр килү бик куанычлы. Алар хезмәттәшләренең тәҗрибәсен үзләштерә һәм лаеклы рәвештә матур традицияләрне дәвам итә. ■

*Каждая библиотека неповторима своей историей, своими читателями и библиотекарями, посвятившими себя служению этому благородному делу. В статье рассказывается о библиотекарях по призванию, внесших значительный вклад в развитие и становление МБУ «Арская ЦБС».*

***Әлфия ГАЛИМОВА,***
*Үзәк китапханәнең халыкка хезмәт күрсәтү бүлеге мөдире,*
*Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре*

# «Илһам – күңел канаты»

## («КАУРЫЙ КАЛӘМ» ӘДӘБИ-ИҖАТ БЕРЛӘШМӘСЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ)

МИЛЛӘТЕБЕЗГӘ йөзләрчә күренекле шәхесләрне, 60 лап мәгърифәтче, 70 тән артык профессионал язучыны биргән Арча районында хәзерге көндә 50 гә якын һәвәскәребез иҗат итә. Үзәк китапханә каршында «Каурый каләм» әдәби-иҗат берләшмәсе эшләп килә. Берләшмә үзенең эшчәнлеген 1980 елда башлап җибәрә һәм ул «Тукай якташы» исемен йөртә. Аның җитәкчесе – Ф.Хөсни премиясе лауреаты, прозаик Р.Фәизов була. Ул бакыйлыкка күчкәннән соң, берләшмәнең эшен танылган мөгаллимә, Халык мәгарифе отличнигы, хезмәт ветераны Нәҗия ханым Саттарова алып барды. Нәҗия ханым, өлкән яшьтә булу сәбәпле, бу җаваплы вазыйфаны 5 нче гимназиядә озак еллар татар теле һәм әдәбияты укыткан ярдәмчел, ару-талуны белмәс хезмәт ветераны Фәйзрахманова Халидә Габделхак кызына тапшыра. Халидә ханым җитәкчелек иткәндә, берләшмә «Каурый каләм» әдәби-иҗат берләшмәсе дип атала башлый. Бүгенге көндә «Тукай якташы» берләшмәсе балалар иҗат йортында үзенең эшен укучы яшьләр белән алып бара.



*Әлфия Галимова*

2010 елдан башлап, «Каурый каләм» әдәби-иҗат берләшмәсе эшчәнлеген Арча үзәк китапханәсендә дәвам итә. Берләшмәгә сүз тәмен белгән, иҗади рухлы, рус һәм татар телендә иҗат итүче утыздан артык кеше йөри. Аларның иң яшенә 21 яшь булса, иң олысына – 84 яшь. Берләшмәдә композиторлар, җырчылар, нәфис сүз осталары да бар. «Каурый каләм»леләр төрле темаларга иҗат итәләр. Шигырьләрендә туган якка чиксез мәхәббәт, яшәү мәгънәсе турында уйланулар, сугыштан соңгы авыр, михнәтле тормыш, кабатланмас балачак истәлекләре, һәм, әлбәттә, мәхәббәт кичерешләре дә чагылыш таба. «Каурый каләм»леләр китапханәдә ай саен җыелып әсәрләрен тикшерәләр, фикер алышалар. Соңгы 4-5 ел эчендә егермегә якын һәвәскәр язучының китаплары басылып чыкты. Тагын дүртесенең китап итеп бастырырлык шигырьләре бар.

«Каурый каләм»леләр Татарстан Республикасы Язучылар берлеге белән һәрдаим элемтәдә торалар. Кураторлары – якташыбыз, шагыйрь, профессор Рифат Җамал. Берләшмә әһелләре район күләмендә уза торган чараларга яратып йөриләр, мәктәпләрдә, уку йортларында аларны көтеп алалар. Әдәби мәйданнарда, паркларда ялкынлы чыгышлар ясыйлар, Республикада, район күләмендә узган бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар алалар. Араларында халык арасында танылып, социаль челтәрләр аша популярлык казанган, иҗатларына дәрәҗәле язучылар бәя биргән

шагыйрь һәм шагыйрәләребез Нажия Саттарова, Минһаҗ Кашапов, Роза Шәйхетдинова, Факия Шәрәфетдинова, Гөлсинә Зәкиева, Дамир Нуриәхмәтов, Марсель Шәрәпов, Гөлара Шәрипова бар.

Арча муниципаль район хакимияте һәвәскәр язучыларны игътибар үзәгендә тота, китапларын бастырып чыгаруда ярдәм кулын суза. 2015 елда, «Әдәбият елы» уңаеннан, «Каурый каләм»нәрнең иҗатын берләштергән «Шигъри тәлгәшләр» җыентыгы дөнья күрде. 2016 елда мәктәп укучылары өчен «Мәгариф-Вакыт» нәшриятында 3 томнан торган «Без бит – Арча яклары» исемле, Арча төбәге әдипләре иҗатын чагылдырган китап-хрестоматияләр басылды. Әлеге китапларда һәвәскәр язучыларның әсәрләре дә урын алуы – алар өчен зур дәрәҗә.

Арчабызда яшәп иҗат итүче, «Кичә ярattым» исемле повесть, хикәяләр китабы авторы Зиннур Тимергалиев 2018 елда Татарстан Республикасы Язучылар берлегенә кабул ителде. Хәзер районыбызда Радик Фәизовның эшен дәвам итүче якташыбыз булуы белән без горурланабыз һәм Зиннурга иҗади уңышлар телибез.

Китапханәчеләр һәвәскәр язучыларның иҗатын халыкка җиткерүне күздә тотып, иҗат кичәләре уздыра, яңа китапларын тәкъдир итә, «Каурый каләм»нәр белән берлектә радиотапшырулар алып бара, әдәби марафоннар, иҗади бәйгеләр оештыра.


«Ызандашлар» очрашуы

Язучыларыбыз бик тә актив, 7 районның иҗат төркемнәре белән элемтәгә кереп, үзара кунакка йөрешәләр, иҗатларын бер-берсенә тәкъдим итәләр. Социаль челтәрдә «Ызандашлар» (яшьләр), «Дуслык» (өлкәннәр) төркемнәрен булдырдылар. Яшьләр төркеме белән якташыбыз, прозаик Зиннур Тимергалиев җитәкчелек итә.

«Казан утлары», «Идел», «Сөембикә» журналлары, «Ватаным Татарстан», «Шәһри Казан», «Арча хәбәрләре» газеталары битләрендә якташларыбызның иҗаты яктыртыла. Һәвәскәрләребез «Болгар» радиосының «Яшәү яме» тапшыруында, «Курай», «Арча» радиосында Республика, районыбыз халкын үзләренең иҗатлары белән таныштыруны дәвам итәләр. Алар 3 тапкыр «Башваткыч»та да катнашып, уңышлы чыгыш ясадылар. Татарстан Республикасы мәдәният министры И. Х. Әюпова үзләрен Ш.Камал музеена кунакка да чакырып китте.

Үзәк китапханәнең «Туган як бүлмәсе»ндә һәвәскәрләрнең иҗатын чагылдырган бай күргәзмә эшли. Биредә китаплар белән бергә һәркайсының иҗаты, тормыш юлы тупланган папкалар да бар.

«Арча хәбәрләре» газетасы журналисты, «Җидегән чишмә» халык театры артисткасы, «Ташлап китмә» пьесасы, хикәяләр, шигырьләр җыентыгы авторы Гөлсинә Зәкиеваның исеме бөтен Татарстанга билгеле. Аның пьесалары буенча куелган спектакльләрне тамашачы җылы кабул итә. «Ирләр дә елый икән» пьесасы буенча районыбызда тулы метражлы нәфис


«Каурый каләм»нәр «Болгар» радиосында

фильм да төшерелде.

Казанбаш авылында яшәп иҗат итүче 4 егет анасы, «Баллы күзләрем» исемле шигырьләр китабы авторы Гөлара Шәрипова иҗаты да игътибарга лаек. Аның шигырьләрен хәзер күрше республика, өлкәләрдә яшәүчеләр дә яратып укыйлар. Без, китапханәчеләр, якташларыбызның киләчәктә дә яңадан-яңа иҗади биеклекләр яулавын теләп калабыз. Якташыбыз Наил Касыйм да үзенең «Казан арты» шигырендә һәвәскәрләргә әнә нинди зур ышаныч белдерә:

**Казан арты горурланып яши,**
**Искә алып данлы улларын,**
**Нык ышанам: шул халыктан әле**
**Яңа Тукайларның туарын!**

*При Центральной библиотеке г. Арска с 2010 года работает литературно-творческое объединение «Каурый каләм», куратором которого является поэт, академик, профессор Рифат Джамал. «Каурый каләм» объединяет более тридцати талантливых самодеятельных поэтов, прозаиков и драматургов. В 2018 году член объединения Зиннур Тимергалиев стал членом Союза писателей РТ. Руководитель объединения – учитель татарского языка и литературы Халида Файзрахманова. Члены объединения – люди активные и позитивные. Они посещают культурные мероприятия республики и района, ежемесячно собираются в библиотеке, проводят мастер-классы, обсуждают свои произведения. За последние 5 лет было издано около 20 книг самодеятельных авторов. Библиотекари активно пропагандируют их творчество, проводят творческие вечера, презентации книг, готовят радиопередачи.*

***Илсөяр ХӘНӘФИЕВА,***
*Үзәк китапханәнең әйдәп баручы библиографы*

# Ихтирамга лаеклы шәхес

АРЧА үзәкләштерелгән китапханәләр системасы тарихы белән генә түгел, китапханәдә гомер буе эшләп лаеклы ялга чыккан һәм хәзерге көндә җаны-тәне белән халыкка хезмәт итүче китапханәчеләре белән дә горурланып яши.

Арча Үзәк китапханәсенең өлкәннәргә хезмәт күрсәтү бүлеге мөдире Галимова Әлфия Нәкыйп кызы әнә шундыйлардан. Ул Арча районы Гөберчәк авылында туа. Әдип М.Мәһдиев әсәрләрендә тасвирланган Сафый чишмәләренең суын эчеп, гүзәл табигатьле урманкырларның гүзәллегенә сокланып үскәнгәдерме, Әлфия апа бик мөлаем, нечкә күңелле, сабыр, тырыш ханымнарның берсе.

Ул тормышының матур мизгелләрен туган авылы белән бәйли. Мәктәп елларында бик тырышып белем ала. Бигрәк тә гуманитар фәннәрне ярата. Мәктәпне тәмамлау белән, мәдәният-сәнгать институтының китапханәчеләр әзерләү бүлегенә укырга керә. Укуны тәмамлап, кулга диплом алуга ике ел Казанда китапханәдә эшли.

Әмма, нәрсә дисәң дә, Әлфия ханымны туган яклары, Арча төбәге үзенә тарта. 1984 елның августыннан Арча Үзәк китапханәсенең китап туплау һәм эшкәртү бүлегендә баш мөхәррир булып эшли башлый, ике елдан соң өлкәннәргә хезмәт күрсәтү бүлеге мөдире итеп күчерелә.



Илсөяр Хәнәфиева

33 ел Әлфия ханым китапханәнең, китапханәче һөнәренең бөтен нечкәлекләрен белеп, аңлап, эштә булган һәр көненнән, һәр сәгатеннән тәм табып, ләззәт алып яши. Аны барлык китап укучылар да бик ярата, хөрмәт итә, чөнки китап укучыларга һәрвакыт яхшы мөгамәләдә, мөрәҗәгать белән килгән берәүне дә кире бормый. Ул, гомумән, беркайчан бер кешегә дә авыр сүз әйтми, тыныч, итәгатьле, әңгәмәдәшен һәрвакыт тыңлап бетерә һәм үзенең төпле, акыллы киңәшләрен бирә. Аның сөйләм теле бик бай, шуның белән ул күпләрне үзенә җәлеп итә.

Әлбәттә, без, яшь буын, аннан үрнәк алырга тырышабыз,

үзебез белмәгәннәрне Әлфия ханым белән киңәшләшәбез. Яшь китапханәчеләр өчен ул – тәҗрибәле остаз.

Гаиләсендә ул бик сабыр, акыллы, уңган хатын, ике кызына кайгыртучан әни, оныклары өчен кадерле дәү әни.

Әлфия Нәкыйп кызы бай һөнәри белемле, татар әдәбиятын яхшы, тирәнтен белүче хезмәткәр. Район күләмендә узучы зур чараларга, әдәби кичәләргә, язучышагыйрьләр, күренекле һөнәр ияләре белән очрашуларга сценарийларны гадәттә Әлфия ханым яза. Мондый чаралар тирән эчтәлекле һәм һәркемнең күңел түренә үтеп керерлек мәгънәле була.

Хәзерге көндә китапханәгә укучыларны җәлеп итү җиңел түгел. Күренекле шәхесләр белән очрашу кичәләре, түгәрәк өстәлләр генә оештырып калмыйча, яшь һәм өлкән буын китап укучыларын төрле кызыксыну клубларына да җәлеп итә Әлфия ханым. «Яшәү яме», «Каурый каләм» клубларында безнең өлкән буын китап укучылар, каләм тибрәтүчеләр очраша. Алар әлеге очрашуларда яңа китаплар белән танышалар, үзләренең иҗат җимешләре, шулай ук яңа басылып чыккан китаплары белән дә таныштыралар.

Өлкәннәргә хезмәт күрсәтү бүлеге Әлфия ханым җитәкчелегендә, программаларга нигезләнеп, тулы эш алып бара.

2009 елдан башлап, яшь талантларны барлау һәм аларның иҗатын камилләштерү максатыннан, Татарстанның халык язучысы Г.Ахунов премиясен тапшыру, М.Мәһдиев укуларын уздыру кебек җаваплы чаралар Әлфия Нәкыйповнаның төпле киңәшеннән башка узмый.

Үзәк китапханәдә сукырлар һәм начар күрүче китап укучыларыбызга ярдәм йөзеннән Әлфия ханым аерым бүлмә




*Өлкәннәргә хезмәт күрсәтү бүлеге мөдире Галимова Әлфия Нәкыйп кызы*

ачты. Ул Республика сукырлар китапханәсеннән махсус китапларны почта аша кайтарта һәм укучыларга тәкъдим итә.

Әлфия ханымның хезмәтләре хөкүмәтебез тарафыннан югары бәяләнде: мәдәният өлкәсендә зур уңышларга ирешкән өчен Мәдәният министрлыгының һәм Россия хөкүмәтенең Мактау грамотасына, «Иң яхшы һөнәр иясе», «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменренә лаек булды.

Әлфия Нәкыйповнаның хезмәт юлы бай һәм эчтәлекле. Ул – хезмәткәрләре арасында хөрмәт яулаган, ихтирамга лаеклы шәхес. Һәрвакыт китапханә эшендә яңа юнәлешләр эзли, замана белән бергә атларга тырыша, һөнәри белемен арттыру өчен яңа әдәбият, һөнәри журналлар белән һәрдаим танышып бара. ■

*Большую роль в развитии библиотеки играют ее кадры: авторитет и профессионализм, интеллектуальный уровень, умение работать с партнерами, позиционировать себя в обществе. Галимова Альфия Накиповна, которая долгие годы возглавляет отдел обслуживания взрослых Центральной библиотеки Арской ЦБС, является примером библиотекаря высокой квалификации. С первых дней работы в библиотеке и до сегодняшнего дня все ее помыслы связаны с библиотекой. Под ее четким руководством воспиталось несколько десятков молодых библиотекарей.*

● ИҖАДИ ОЧРАШУЛАР
● ТВОРЧЕСКИЕ ВСТРЕЧИ

*Сәфәр ГӘРӘЕВ*

# Бөек шагыйрь җирлегендә



Разил Вәлиев

## ТАТАРСТАННЫҢ ХАЛЫК ШАГЫЙРЕ РАЗИЛ ВӘЛИЕВ БЕЛӘН ОЧРАШУ

«АРЧА ягы – Тукайлы як!», дип горурланып әйтәбез. Ә Тукайны бөтен татар халкы үз итә, ярата, Тукайны бөтен төрки дөньясы хөрмәтли. Тукай үзе белән бергә безнең төбәкне, Арча ягын да дөньяга танытты. Арчага килүче кунакларның, туристларның саны елдан-ел арта бара. Аларны монда Тукай иҗаты, Тукай рухы, чын татар мохите чакырып китерә.

Ә без бу юлы Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Разил Вәлиевне үзебез кунакка чакырдык. Дөрес, моңа кадәр дә ул ел саен апрель аенда уза торган Тукай бәйрәмнәренә килмичә калмый иде. Ә безнең аны уртак олы бәйрәмгә түгел, аерым гына чакырып, иркенләп фикер алышасыбыз, әңгәмә корасыбыз, үз авызыннан шигырьләрен ишетәсебез килгән иде.



Разил Вәлиев китаплары күргәзмәсе

«Без» дигәнем – район китапханәчеләре, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, җирле шагыйрьләр, журналистлар, мәдәният хезмәткәрләре. «Бәхетле талант» дип аталган әлеге очрашу кичәсен ачып җибәргән мәдәният идарәсе җитәкчесе Рамил Мөхетдинов сүзен кыска тотты. «Разил Вәлиев белән озаклап таныштырып тору кирәк тә түгелдер, чөнки сез аны барыгыз да яхшы беләсез. Халкыбызга ул шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе буларак яхшы таныш булса, ә без, мәдәният хезмәткәрләре, аны якын дустыбыз һәм яклаучыбыз буларак ихтирам итәбез. Аның ярдәме белән республикада дистәләгән клублар, китапханәләр, мәктәпләр, балалар бакчалары төзелде яисә ремонтланды. Аның ярдәме белән хезмәт хакыбыз күтәрелде, китапханә фондларыбыз тулыланды», – дип башлады ул сүзен һәм кичәне алып бару дилбегәсен Үзәк китапханәнең бүлек мөдире Әлфия Галимовага тапшырды.

Алып баручы исә шул урында очрашуның рәсми өлешенә нокта куеп, безне шигърият дөньясына алып кереп китте:

*«Елый-елый,*
*сугыша-сугыша җирдә*
*Акыл күпме җавап эзләгән...*
*Йә дөньяны үзгәртәм мин бүген,*
*Йә, булмаса, үзем үзгәрәм.*

Үз-үзенә ышанган, көчле рухлы кеше генә мондый шигырьләр

иҗат итә ала. Туган җир, ата-ана хакы, табигать, милләт язмышы турында уйлануларыгыз аеруча көчле. Әлбәттә, мәхәббәт һәм яшьлек темалары да сезнең иҗатта төп урынны алып тора», – дип мөрәҗәгать итте ул шагыйрьгә. Аннары бу очрашуны чын-чынлап иҗат кичәсенә әверелдерү өчен җырчыларга сүз бирде. Ә аларның сүзе, билгеле, җыр телендә иде. Разил Вәлиев шигыренә язылган «Ядкарь» җырын бөтен зал Расих Галимҗановка кушылып җырлады. «Разил Вәлиевкә «халык шагыйре» исемен юкка гына бирмәгәннәр икән», – дип уйлап куйдым мин шулчак.



Китапханә буйлап сәяхәт

Минем уйларымны белгәндәй, ул «Ядкарь» җырының язылу тарихын сөйләп китте. Узган гасырның 80 нче елларында Актёрлар йортында гөрләп барган «Ядкарь» кичәләре өчен, әдип һәм режиссёр Рабит Батулла соравы буенча, бу җырны алар композитор Фасил Әхмәтов белән махсус язган булганнар икән.

Залда утыручылар җырдан соң, кул күтәреп, шагыйрьгә сораулар яудыра башладылар.

**– Сезгә, белүебезчә, Мәскәү Әдәбият институтында уку насыйп була. Бу чор хәтерегездә ничек сакланып калган?**

*– Түбән Камада урта мәктәпне тәмамлагач, мин ике ел Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укыдым. Әдәбият институтына керү өчен, башта иҗади конкурс үтәргә кирәк, – дип башлады сүзен Разил Вәлиев. – Конкурстан узгач, документларны алу өчен, деканатка кердем, ә анда доцент, Муса Җәлилнең якын дусты Гази Кашшаф утыра. «Университетка кергәндә, мин сиңа ни өчен монда укырга ниятләвең турында сорау биргән идем. Син ул чак: «Чөнки монда Ленин укыган, Толстой укыган», – дип әйткән идең. Ә хәзер ни өчен китәсең?» – дип, усал итеп карап куйды Гази ага. Ә мин, бераз уйлап тордым да: «Чөнки Ленин киткән, Толстой киткән!» – дип әйтеп салдым.*

*Менә шулай итеп мин Мәскәүгә китеп бардым. Ә Мәскәү олы дөньяга күзләремне ачты. Әдәбият институтында СССРның төрле республикаларыннан, дөньяның төрле илләреннән җыелган яшь иҗатчылар укый иде. Алар белән аралашу, атаклы шагыйрьләрдән, язучылардан, галимнәрдән белем алу минем рухи дөньямны баетты, уй-фикерләремә хәрлек өстәде.*

*Мәскәүдә мин гаилә кордым, монда кызым Сөембикә туды, монда укыганда, беренче китабым дөнья күрде.*




Разил Вәлиев сүзләренә җыр яңгырый

Залдан яңгыраган икенче сорау гаилә турында булды:

**– Чит шәһәрдә студент килеш ничек гаилә корып, аны яшәтә алдыгыз?**

*– Хәзер үзем дә шуңа аптырыйм. Ә ул чакта кыюрак, юләррәк булганмындыр инде. Бала белән яшәргә ярамый дип, тулай торактан чыгаргач, Мәскәү читендәге бер ярымҗимерек дача сыман йортка килеп урнаштык. Аңа түлисе, өч кешелек гаиләне ашатасы, киендерәсе бар, ә стипендия 28 сум. Җан асрарлык акча эшләү өчен автомобиль заводының тимерчелек цехына төнге сменага эшкә кердем. Кичке 11 дән иртәнге 7 гә кадәр эшләп, институтка килгәч, лекциядә йоклап киткән чаклар да булгалады. Ә шулай да Мәскәү минем өчен бик тә зур мәктәп булды – тормыш һәм иҗат мәктәбе.*

**– Беренче повестегез «Эт кояшы» да, беренче җырыгыз «Дулкын» да Мәскәүдә язылган бит...**

*– Әйе. Повесть язарга мине мәшһүр әдибебез*



Балалар Разил Вәлиев шигырьләрен укый



Әхәт Мушинский Татар ПЕН үзәге турында сөйли

*Аяз ага Гыйләҗев «котыртты». Мәскәүгә бер килгәндә, ул: «Шигырь язу – яшьлек галәмәте, ә яшьлек бик тиз уза ул. Проза язарга кирәк, проза гомерлек», – дип әйткән иде. Шуннан соң атна-ун көн эчендә, көне-төне утырып, «Эт кояшы» повестен яздым. Аны укып чыккач, Аяз ага кульязманың соңгы битенә: «Шәп! Лихо!» – дип язып та куйган иде. Әмма бу повестьнең язмышы катлаулы булды. «Совет чынбарлыгын каралтып күрсәтә», – дип, аны беркайда да бастырмадылар. Ул 21 ел узганнан соң гына дөнья күрде. Ә «Дулкын» җырын – беренче җырымны – яздыручы бөек җырчыбыз Илһам Шакиров булды. Ул мине Мәскәүдәге тулай торактан эзләп табып, пластинкага яздыру өчен, халык көенә тиз генә сүзләр язып бирүемне сорады. Анысын ошаткач, Илһам ага соравы буенча бербер артлы «Бер алманы бишкә бүләек», «Таң җыры» өчен шигырьләр яздым. Әдәбият институтында иҗат семинарымдагы җитәкчем дә – йөзләгән матур җырлар авторы, мәшһүр шагыйрь, профессор Лев Ошанин иде. Мена шушы ике бөек зат мине, ике кулымнан җитәкләп, җыр дөньясына алып кереп китте.*



Истәлеккә автограф

**– Сез берьюлы берничә жанрда: поэзия, проза, драматургия, публицистика жанрларында иҗат итәсез. Бер жанрдан икенчесенә күчү кыен түгелме?**

*– Мин аның авырлыгын сизмим. Чөнки төп жанрым итеп шигъриятне саныйм. Ә шигырь язган кешегә, гадәттә, прозага, драмага күчү зур кыенлык тудырмый. Ә теләсә кайсы прозаик яисә драматург шигырь яза алмый. Дөрес, арада бөтен жанрларны «йөгәнли алучылар» да очрый. Мәсәлән, Туфан Миңнуллин.*

**– Разил әфәнде, әсәрләрегездәге геройларның прототиплары кемнәр?**

*– Нигездә, мин үзем күргән вакыйгалар, үзем белгән кешеләр турында язам. Ләкин аларны үз фантазиям, хыялым белән баетам, аларга яңа төсмерләр, яңа сыйфатлар өстим. Минемчә, әдәби әсәрнең үзәгендә кеше язмышы, милләт язмышы ятарга тиеш. Шулай булганда гына язучы үз максатына ирешә, халык аны ихластан кабул итә.*

**– Хөрмәтле Разил Исмәгыйль улы, без Сезнең озак еллар Татарстан Милли китапханәсе директоры булып эшләвегезне беләбез. Ул чорда китапханә дөньясындагы уңай үзгәрешләрнең дә Сезнең эшчәнлек белән бәйле булуын хәтерлибез. Сез әле бүген дә Милли китапханәнең Кайгыртучылар шурасы рәисе. Шуңа күрә бу соравыбыз китапханәләр һәм китаплар язмышы турында булыр.**

**Яңа технологияләр һәм Интернет чорында китапханәләрне нинди язмыш көтә? Электрон китап традицион кәгазь китапны мәйданнан кысрыклап чыгармасмы?**

*– Мондый сорауларны бик еш ишетергә туры килә миңа. Моңа охшаш сорауларны моннан йөз ел элек тә бирә торган булганнар. Фотография барлыкка килгәч, рәссамнарның кирәге бетә дигәннәр. Кино төшерә башлагач, театрга да шундый язмыш юраганнар. Әмма*




*Бергә булыйк!*

*бүген фотографлар белән янәшә рәссамнар, кино белән янәшә театр да бик матур яшәп килә. Минемчә, китапханәләр беркайчан да бетмәячәк. Аларның бары тик эш алымнары гына үзгәрәчәк. Аң-белем эстәү, мәгълүмат үзәге булу белән бергә, алар кешеләр өчен җанлы аралашу урынына әвереләчәк. Ә традицион, гадәти китап белән электрон китап берберсен тулыландырып, бер-берсен баетып янәшә гомер итәчәк.*

Разил Вәлиев сүзләренә язылган җырлар, ул иҗат иткән шигырьләр, кызыклы сораулар һәм тәфсилле җаваплар белән үрелеп барган бу кичәне һич кенә дә тәмамлыйсы килми иде. Залда шагыйрьгә сорау бирергә, сүз катарга атлыгып торучылар артканнан арта гына барды.

– *Мин 30 ел буе Дәүләт Советында депутат булдым,* – дип сүзен дәвам итте Разил Вәлиев. – *Анда сәгать ярым саен тәнәфес ясый торган идек. Ә безнең бу кичә инде ике сәгать дәвам итә. Аннары Дәүләт Советында бер кешегә сөйләү өчен ун минут кына вакыт бирелә. Әйдәгез, хәзер сүзне күренекле язучыбыз, Г.Державин премиясе лауреаты Әхәт Мушинскийга тапшырыйк.*

Әхәт әфәнденең чыгышы озын булмады. Ул үзе җитәкчелек иткән «Казанский альманах» һәм Татар ПЕН-үзәге турында сөйләде. Аннары Милли китапханәдә 1996 елдан бирле чыгып килгән «Китапханә хәбәрләре» журналы хакындагы фикерләре белән уртаклашты, аның киләсе саны Арча китапханәләренә багышланачагын да әйтеп узды. Үз иҗаты белән дә таныштырды.

Очрашуның тәмамлануын игълан итеп, язучылар Разил Вәлиев белән Әхәт Мушинскийга, Милли китапханә хезмәткәре Зәйнәп Җамалиевага рәхмәтләр әйткәч тә, халык таралышырга ашыкмады. Разил Вәлиевтән автографлар алу өчен халык чиратка тезелде, аннары бер-бер артлы да, күмәкләп тә фотога төштеләр, Арча шагыйрьләре кунакларга үз китапларын бүләк итте.

Бу очрашу чын мәгънәсендә җыр һәм шигырь бәйрәменә, китап һәм китапханә тантанасына әверелде. ■

*В Центральной библиотеке Арской централизованной библиотечной системы прошла творческая встреча с Народным поэтом Республики Татарстан, лауреатом Государственной премии имени Габдуллы Тукая Разилем Валеевым. В мероприятии приняли участие представители администрации, учителя, журналисты, деятели культуры, библиотекари района. Встреча прошла в теплой атмосфере, где каждый смог задать гостю интересующие его вопросы. Разиль Исмагилович рассказал о своей студенческой жизни, о своих первых произведениях и знакомствах с именитыми писателями, учёными, певцами. Собравшиеся долго не хотели отпускать многоуважаемого гостя. На память у них остались незабываемые впечатления от встречи и общая фотография.*

# Арча – шагыйрьләр ягы

**Габдулла ТУКАЙ** (1986–1913) – бөек татар шагыйре

Кушлавыч авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Биш ай чагында әтисез, дүрт яшь тулгач әнисез кала. Габдулланың балачагы Сасна, Өчиле, Кырлай авылларында, Җаек шәһәрендә уза. Мәдрәсәне тәмамлап, Казанга килгәч, киеренке, җанлы иҗади-рухи тормыш эчендә кайный. XX йөз башында татар шигърияте сәнгати камиллек белән яңа юнәлештә үстереп җибәрә.

## Китап

*Һич тә күңлем ачылмаслык эчем пошса,*
*Үз-үземне күрәлмыйча рухым төшсә,*
*Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны*
*Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә;*

*Хәсрәт соңра хәсрәт килеп алмаш-алмаш,*
*Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш,*
*Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса*
*Хәзер генә сыгълып-сыгълып елаган яшь, –*

*Шул вакытта мин кулыма китап алам,*
*Аның изге сәхифәләрен актарам;*
*Рәхәтләнеп китә шунда җаным, тәнем,*
*Шуннан гына дәртләремә дәрман табам;*

*Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем*
*Була минем юл күрсәтүче йолдызым;*
*Сөйми башлыйм бу дөньяның ваклыкларын,*
*Ачыладыр, нурланадыр күңлем, күзем;*

*Җиңеләнәм, мәгъсумләнәм мин шул чакта,*
*Рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка;*
*Ышанычым арта минем үз-үземә,*
*Өмид берлән карый башлыйм булачакка.*

**Мостафа НОГМАН** (1912–1976) – татар шагыйре, тел галиме

Кызыл Яр авылында сәүдә эше белән шөгыльләнүче урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Казан педагогика техникумын тәмамлый һәм укытучы, Хәрби трибуналда сәркятиб булып эшли, соңгы елларда Казан университетының тарих-филология факультетында студентларга фарсы һәм борынгы татар теле укыта. 1965 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы була.

## Әниләр

Гомер таңнарыбыз аткан көнне
Зарыгу белән көтеп алучы,
Безнең өчен тау кадәрле йөкләр
Күтәрергә әзер калучы –

Әниләр,
Мәрхәмәтле безнең әниләр,
Җиргә матурлыкны,
Илгә батырлыкны
Сез бирәсез, гүзәл әниләр.

Сездә яши сүрелмәслек хисләр,
Йөзегездә – шәфкать нурлары,
Сезнең җырлар аша күчә безгә
Туган халкыбызның моңнары.

Якты йолдыз кебек сез балкыйсыз
Тормыш юлларыбыз күгендә,
Иң кадерле бер кешебез булып,
Сакланасыз күңел түрендә.



**Сания ӘХМӘТҖАНОВА** (1962) – шагыйрә, популяр җыр текстлары авторы

Курса Почмак авылында колхозчылар гаиләсендә дөньяга килә. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һади Такташ исемендәге әдәби премиясе, Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгарифтәге казанышлары өчен» мактау бүләге иясе. 2009 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## Туган-үскән җирләрдә

Җылы яңгыр юып үткән
Җәяүле басу юлын.
Ерактан ук кочак җәеп
Каршылый безне болын.

Өзмик, әйдә, чәчәкләрне,
Үссеннәр матур булып.
Уйнасыннар күбәләкләр,
Шул чәчәкләргә кунып.

Тирбәләләр талгын җилдә,
Ямь биреп Туган җиргә.
Бүләк итәм ал гөлләрне
Болыны белән бергә.

Дөнья якты кояш белән,
Болын яме – гөлләрдә.
Күкләр аяз, күңелдә – яз
Туган-үскән җирләрдә.

**Наил КАСЫЙМ** (1955) – шагыйрь, популяр җыр текстлары авторы

Ашытбаш авылында туа. Казан төзүче-инженерлар институтында белем ала. Татарстан дәүләт телестудиясендә өлкән редактор хезмәтендә, Казан хакимиятенең Мәдәният идарәсендә идарә башлыгының беренче урынбасары булып эшли. 1999 елдан шәһәр хакимиятенең Юллар төзү идарәсендә идарә башлыгы урынбасары вазифаларын башкара. Татарстан һәм Башкортстан композиторлары тарафыннан шагыйрьнең йөзгә якын шигыренә көй язылган.

## Ак яулыклы әнием

Чәчләреңә япкан ак яулыгың
Бик килешә, әнкәм, йөзеңә.
Ак яулыгың төсле ак күңелең,
Саф күңелең чагыла күзеңдә.

Ак төсләрне әллә күп сөйгәнгә –
Чәчләрең дә бүген ак синең...
Күңел күгемдә син – якты кояш,
Ак яулыклы әнием минем!

Ак көннәрең, бәлки, аз булгандыр,
Югалтның шул инде саулыгың.
Кара кайгыларны күрсәң дә син,
Каралтмадың, әнкәм, яулыгың.

Ак төсләрне әллә күп сөйгәнгә –
Чәчләрең дә бүген ак синең...
Күңел күгемдә син – якты кояш,
Ак яулыклы әнием минем.

**Рифат ҖАМАЛ** (1951) – шагыйрь һәм галим

Миргәм авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Казан ветеринария институтында югары белем ала. Шушы өлкәдә галим буларак, дистәләрчә фәнни хезмәт, мәкаләләр, татарча язылган берничә гыйльми китап авторы. Фән өлкәсендәге казанышлары өчен Татарстан Республикасының Дәүләт премиясенә лаек була. 1998 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

## *Балачакта...*

Балачакта Сабантуйда
Колгага менгән идем.
Чайкалган колганы түгел,
Үземне җиңгән идем.

Ә шулай да, юкка булган
Менгәндә куркуларым.
Төшкәндә яндылар минем
Тезләрем вә кулларым.

Олайсам да, әле һаман
Белмимниләр буласын.
Тик менгәнче кая булса,
Төшүеңне уйла син!

**Марсель ШӘРӘПОВ** (1961)

Сарай-Чокырча авылында дөньяга килә. Авыл хуҗалыгы институтында белем ала. 22 ел Эчке эшләр органнарында хезмәт итеп, майор дәрәҗәсендә отставкага чыга. Хәзерге вакытта туган авылының мәдәният йортында директор булып эшли. «Әткәй тальяны» дип исемләнгән китап авторы.

## *Галиҗәнап вакыт*

Галиҗәнап вакыт! Кайтар мине
Бер гөнаһсыз бала чагыма –
Сабый җаным уйнап туймады ла
Туган йортта, туган ягымда!

Галиҗәнап вакыт! Зинһар, кайтар
Кукрәп үткән үсмер чорыма –
Әйтелмәгән яшерен серем калды
Җандай газиз тәүге ярыма!

Хисләремне көйгә салып җырлыйм,
Ярсып тартып баян күрүгән...
Без аттырган таң яктысын сорый
Картаюны белмәс күңелем!

Галиҗәнап вакыт! Юк, кайтарма,
Калыймчы мин шушы чорымда –
Өр-яңадан күңел чәчәк ата
Яңа туган яшьлек җырымда!

**Гөлара ШӘРИПОВА** (1974)

Иске Төрнәле авылында туып үсә. Һөнәре буенча – укытучы. 1994 елда Арча педагогия училищесын тәмамлый, аннары югары белем ала. Баштарак үзе өчен генә шигырьләр язса, алга таба башкалар белән дә бүлешә башлый. 2017 елда «Ак бүре» нәшриятында «Баллы күзләрем» исемле шигырь китабы басылып чыкты.

## *Тормыш китабы*

Тормыш бит ул матур китап кебек,
Язучысы аны – үзебез.
Укыганда, ачып, дус-туганнар,
Кызармасын иде йөзебез.

Яхшылыклар белән тулып торсын,
Изге эшләр аны бизәсен.
Кара таплар, начар эш-гамәлләр
Тормыш китабына кермәсен.

Тормыш бит ул матур китап кебек,
Ничек язу тора үзеңнән.
Язмышларны сылтау итеп кенә
Җаваплылык төшмәс иңеңнән.

Язык әле, язык матур китап,
Бездән соң да сагынып укырлык.
Җир йөзендә ни бар кадерлерәк,
Кеше гомеренә торырлык?!



**Надия ЙОСЫПОВА** (1969)

Яңа Кишет авылында туа. Хезмәт юлын Яңа Кишет сигезьеллык мәктәбендә пионервожатыйкитапханәче булып башлап җибәрә. 1989–1991 елларда Алабуга мәдәният училищесының китапханә эше бүлегендә белем ала. 1988 елдан хәзергә кадәр Яңа Кишет авылында китапханәче хезмәтен башкара. 2017 елда «Хисләремнән сәйлән тезәм» исемле шигырьләр җыентыгы дөнья күрде.

## *Китапханәче*

Китап тора түр башында,
Туплаган тарих серен,
Китап – мирас бакчасының
Сулыкмас тере гөле.

Китап уку рәхәтлеген
Кем татымый, шул белми,
Күпме аңнар биктә ята
Китапханәгә йөрми.

Килә кайчак дөнья гизеп,
Табышмаклар чишәсе.
Шул чагында кирәк китап,
«Китап — белем чишмәсе!»

Иң кирәк киңәшне сиңа
Китапханәче бирә,
Китап яраткан кешенең
Яшәеше дә үзгә!

Кайсы китап нинди телдә,
Китапханәче белә,
Яктылык өстәп яши ул
Һәр туган яңа көнгә.

Күңелләрдән күңелләргә
Илһам нуры салучы,
Юлларыңа гөлләр түшәп,
Сәлам биреп баручы.

Җаныңа җылы өләшеп,
Гыйлем нуры сибүче,
Ярдәм кулы сузып һәрчак,
Сиңа каршы килүче.

Якты карашлары белән
Елмаеп каршылаучы,
Тагын кил! диеп моңаеп,
Сине озатып калучы.

Изге һөнәрләрнең берсе,
Аң-белем өләшүче,
Серле мәгарә хуҗасы –
Кем ул? –
Китапханәче!

• ЭШ ТӘҖРИБӘСЕ
• ОПЫТ РАБОТЫ

*Алсу ЗӘКӘРОВА,*
*методик-библиографик бүлек мөдире,*
*«Ак калфак» иҗтимагый оешмасының*
*Арча бүлекчәсе җитәкчесе*

# «Ак калфак» – халкым нуры

АРЧА ягы – данлыклы Казан артының үзәге. Татар халкының тарихына үзеннән лаеклы өлеш керткән, милләтебезнең рухи нигезен нығытучы, халкыбызның сөйләм һәм әдәби телен саклап калучы як ул! Арчабызның күп гасырлык тарихы, мәдәни, сәяси һәм икътисади традицияләре бар. Гасырлар дәвамында алар безнең җирлектә үсеп ныгый барган. Арча ягы үзенең бөек мәгърифәтчеләре, күренекле язучылары, сәнгать эшлеклеләре, галимнәре, тырыш һәм эш сөючән халкы белән дә данлыклы.

Соңгы елларда халкыбызның туган җиренә, туган теленә, үткәненә, мәдәниятенә игътибары арткannan-арта бара. Бу үзгәреш йола, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәрне үткәрүгә, онытылганнарын торгызуга һәм яңартуга китерә.

2016 елдан районыбызда китапханәләр каршында татар хатын-кызлары мәнфәгатьләрен кайгыртучы, гаилә, туган телебез, гореф-гадәтләребез, йолаларыбыз сагында торучы «Ак калфак» оешмасы хәрәкәте җанланып китте, һәр китапханә каршында «Ак калфак» клублары эшли башлады. Авыл китапханәләре каршында оешкан 50 бүлекчә даими эш алып бара. Аларның максатлары: яшь буынны милли рухта тәрбияләү, халкыбызның гореф-гадәтләрен таныту, китапханә чаралары аша татар телен үстерү, мөслимәләр белән очрашып, динебезнең асылын аңлату, көндәлек киемгә милли үрнәкләрне кертү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау. Китапханәләрдә «Ак калфакны төшермик кулдан», «Ак калфакның энҗеләрен бөртекләп җыяр чаклар» дигән китап күргәзмәләре халыкка тәкъдим ителде. Тәҗрибә уртаклашуны күздә тотып, газета- журналларда «Ак калфак» иҗтимагый оешмасының эшчәнлеген чагылдырган мәкаләләр дә әлеге күргәзмәләрдә урын алды.



*Мунчала үрү күренеше*

«Ак калфак» оешмасы кысаларында үткәрелгән чараларда гореф-гадәтләребез, татар милли киемнәре, телебезне саклау хакында фикер алышабыз, яшьләребезне гореф-гадәтләребез, йолаларыбыз аша, уңай мисаллар йогынтысында тәрбия кылырга кирәклеге турында сөйләшәбез. Һәр оешма үзенең эшен план нигезендә алып бара. Төрле чаралар үткәргәндә район җитәкчелегенең ярдәмен тоеп эшлибез.

Районыбызда мәдәниятне үстерүгә, яшь буынны милли рухта тәрбияләүгә, татар телен камилләштерүгә зур игътибар



*Ипи пешеру күренеше*




*«Мин татар малае» бәйгесе*

бирелә. Авылларда милли йолаларны кайтару буенча күп чаралар үткәрелә. Аларда «Ак калфак»лылар башлап йөри, теләп катнаша. Кич утыру, аулак өй, кичке уен, килен төшерү, каз өмәсе кебек халкыбызның энҗе-мәрҗәннәргә тиң күркәм гореф-гадәтләре искә төшерелә. Аларның кайберләренең матур үрнәкләре әле дә саклануы күңелне сөендерә. Мәдәният йортлары каршында эшләүче фольклор коллективлары «Ак калфак» оешмалары белән берлектә шул йолаларны барлап, халыкка җиткерергә тырыша. Урта Сәрдә авылының «Нур» фольклор коллективы тәкъдим иткән «Кодаларны кунакка чакыру», Кышкар авылында «Зөбәрҗәт» фольклор коллективы «Сөннәт котлау» йоласы күренешләре барыбызны да еракларга, әби-бабаларыбыз яшәгән чорга алып кайтты. Ашытбашта «Боз озату», Орнашбашта «Мунчала үрү», Кышкарда «Угыз коймагы», Сөрде, Лесхоз мәдәният йортларында «Орчык бәйрәме», Иске Кырлайда «Кич утыру», Шурада «Печән өсте», Ташкичүдә «Бишек туе», Күпербашта «Кунак кызын сынау», Яңасалада «Нардуган», Яңа Кишеттә «Язны каршы алу», Урта Курсада «Сепарат аерту» күренешләрен сәхнәләштереп авылдашларына тәкъдим иттеләр.

«Ак калфак» иҗтимагый оешмасы, китапханәчеләр, мәдәният хезмәткәрләренең бердәм хезмәте белән оештырылган чараларның тәрбияви әһәмияте дә зур. Менә аларның кайберләре: Үзәк китапханәдә үткәрелгән «Исем – нәселнең йөзе, байрагы!», Т. Миңнуллин исемендәге Яңа Кенәр авыл китапханәсендә «Ныклы гаилә ил терәге», «Исемең матур кемнәр куйган», Сежедә «Ак калфакның табылган чагы», Яңа Кишеттә «Күңелләргә нур сибәсең, әй, Ак калфак!», Яңа Кишет, Кышкар китапханәләрендә үткән «Мөнәҗәтләр – күңел көзгесе», Гөберчәктә «Җәүһәрләрне барлый «Ак калфак», Урта Пошалымда «Милли хәзинәбезне барлаганда», Ашытбаш авылы мәдәният йортында «Исемнәр бакчасында», «Халкымның күңел бизәкләре», Ташкичүдә «Әбиемнең сандык серләре», Иске Ашыт авылы китапханәсендә «Яулыкларда халык тарихы», Казанбашта «Яшьнәп торсын яшь йөрәк» исемле фольклор, Мөндештә «Бишек җырлары – халкым рухы» дип исемләнгән әдәби-тарихи кичәләр, Лесхозда «Орчык өмәсе», Түбән Атыда «Вәгъдә бүләгем чиккән яулык» исемле конкурслар.

«Ак калфак» хатын-кызлар оешмасының эшчәнлеге күпкырлы, төрле юнәлешләрне үз эченә ала. Шуларның берсе «Оста куллар» дип атала. Нәрсә генә иҗат итми алар?! Күз явын алырлык гөлләр, чәчәкләр, төрледән-төрле башмаклар, нәфис шәльяулыклар, урындык япмалары, чигүле мендәрләр һәм башкалар.... «Кулъяулыгым чигешле, чигешләре килешле» исеме астында уңган хатын-кызларыбыз халык арасында кулъяулык, сөлге, калфак, күкрәкчә, картина чигү буенча осталык дәресләре күрсәтәләр.

Тарих һәм халык... Бер-берсеннән аерылгысыз төшенчәләр. Һәр ил, шәһәр, авылның, хәтта аерым бер нәселнең үзенчәлекле үткәне, тарихы бар. Борынгы заманнардан ук татар халкында ата-баба нәселен, җиде буынны белү изге бурыч саналган. Мөселман булган кеше үзенең әти һәм әнисе ягыннан җиде буын әби-бабалары рухына дога укырга тиеш була. Шуңа күрә дә ил агалары – аксакаллар үзләренең нәсел агачын барлатканнар һәм үз ыруларының кабатланмас тарихын язып барганнар, шәҗәрәсен барлаганнар, киләчәк буынга ядкарь-истәлек калдырганнар. Әйе, зирәк булган өлкәннәр – буыннар чылбырын өзелмәслек нык җепләр белән бәйләргә тырышканнар. Нәсел шәҗәрәләрен төзүчеләр, үзләренең

тарихларын барлаучылар барлыкка килүе бик куанычлы.

Утар-Аты авыл китапханәсендә буыннар бәйләнеше һәм шәҗәрә турында «Шәҗәрә – безнең тамырлар» дип исемләнгән искиткеч нурлы кичә булып узды. Шулай ук Яңасала, Яңа Кишет, Яңа Кенәр, Зур Бирәзә, Кышкар авылларында шәҗәрәләр төзеп авылдашларына тәкъдим иттеләр. Алар үрнәгендә башкалар да үз нәселләрен барлый башладылар.

Татар халкының гореф-гадәтләре саклануның гаилә өчен ни дәрәҗәдә мөһим булуын ачыклау, татар хатын-кызы образының рухи һәм мәдәни кыйммәтен билгеләү, гаилә ныклыгын күрсәтү, кайнаналары белән дус-тату гомер кичерүче уңган киленнәрне күрсәтү, шулар үрнәгендә яшьләргә чакыру максатыннан «Төп йорт килене – 2016» бәйгесе үткәрелде. 2017 елда бәйгене «Авылым күрке яшь гаилә» исеме белән дәвам иттек, авылда яшәүче үрнәк яшь гаиләләрне барладык. «Ир-ат солтаны» бәйгесен 2018 елда үткәрдек. Нәтиҗәдә, районыбызда алтын куллы ирләр яшәвенә инандык. 2019 елда «Гаҗәеп әби» бәйгесендә һәр авылдан уңган, булган, милләтебезнең киләчәген тәрбияләүче, үзләренең тормыш юллары белән үрнәк булып торучы «Ак әбиләр» барланды. 2020 елда да бәйгенең дәвамы бар. Ул бәйге «Яшәү дәрте бездә сүнмәгән» дип аталачак, анда уңган, җор телле бабайларыбыз көч сынашачак. Менә шундый бәйгеләр аша авылларда тормышны җанландырып җибәрергә була, дип уйлыйбыз.

«Ак калфак» татар хатын-кызлар иҗтимагый оешмасының «Арча төбәгеннән чыккан язучылар әсәрләрендә чагылдырылган йола, гореф-гадәтләрнең бүгенге көнкүрештә кулланылышы» дигән астындагы күчмә утырышның безнең районда үтүе бик табигый. Гасырлар дәвамында халыкның күңеленә сеңгән йола һәм бәйрәмнәрнең рухы безнең төбәктән чыккан, яраткан язучыларыбыз иҗатында киң чагылыш тапкан. Ел дәвамында без китапханәләрдә язучыларыбызның әсәрләрен яңадан бөртекләп укыдык, өйрәндек. Аларда милли йолаларны, гореф гадәтләрне яктырткан күренешләрне табып, халыкка кайтарырга, ул чорда аларның ничек булганын күрсәтергә тырыштык. Якташ язучыларыбыз Г.Бәширов, М. Мәһдиев, Г.Ахунов, Р. Төхфәтулиннар иҗатында безнең яктагы гореф-гадәт, йола һәм бәйрәмнәр турында күп язылa. Буыннан-буынга күчеп килгән рухи байлыкларыбыз бүгенге көннәрдә дә безнең тормышыбызның, яшәешебезнең бизәге булып тора.

Очрашу көннәрендә без язучыларыбыз әсәрләрендә чагылган гореф-гадәтләрне бүгенге көндә кире кайтару, халыкка җиткерү алымнарын күрсәттек. Австралия, Болгария, Швеция, Белоруссия, Казакъстан, Кыргызстан кебек чит илләр, Россиянең төрле төбәкләре, Татарстанның барча районнарыннан килгән кунаклар Арча шәһәре, педагогика көллияте, музейлар, Ташкичү, Яңа Кишет, Кушлавыч, Яңа Кырлай, Курса, Сеҗе авылы җирлекләре, андагы фольклор төркемнәре, мәдәни тормыш һәм йолалар белән таныште. «Ак калфак»лылар Габдулла Тукайның туган авылы – Кушлавыч, Яңа Кырлай авылларында булдылар. «Мулла чишмәсе» ачылышында катнаштылар.

Гомумән, ул көннәрдә районыбызның һәр оешмасы, һәр авылы «Ак калфак» лылар дулкынында яшәде. Төрле фольклор чараларында яше дә карты да теләп катнашты.

Шунысы куанычлы: «Ак калфак» клубы кысасында үткәрелгән һәр чара китап белән бәйләнеп, китапханәче күзлегеннән чыгып әзерләнә. Чараларга әзерлек чорында без иң элек китапка мөрәҗәгать итәбез. Башта тарихи, әдәби китаплардан гореф-гадәт, йола, бәйрәмнәрнең тарихын, эчтәлеген өйрәнәбез. Тупланган мәгълүматтан китап күргәзмәләре төзибез, тамашачыларны алар белән таныштырабыз.

Күргәнебезчә, районыбыз китапханәләрендә татар телен, татар мохитын саклап калу буенча күпкырлы эш алып барыла. Халкыбызның данлы үткәне, гореф гадәтләре, җыр-биюләре, моңнары онытылмый. Дини бәйрәмнәр үткәргәндә, мөнәҗәт, шигърият кичәләрендә китапханәчеләр башлап йөриләр. Милли традицияләребезне яшь буынга тапшыруда үзләреннән лаеклы өлеш кертәләр. ■

*В статье отражена деятельность местной организации татарских женщин «Ак калфак». В каждой сельской библиотеке созданы клубы по возрождению традиций татарского народа. В них уделяется большое внимание пропаганде самобытности и уникальности отечественной культуры, неповторимости и красоты татарских обрядов и обычаев. При проведении мероприятий библиотекари активно используют книги, художественную и историческую литературу, национальную музыку и фольклор.*

***Гульназ КАМАЛОВА,***
*ведущий методист Центральной библиотеки*

# Будущее – это МЫ

РАБОТА с молодёжью – одно из направлений работы массовой библиотеки, требующее постоянного поиска новых идей и замыслов. Однако, как показывает практика, участие самой молодежи в разработке и реализации библиотечных программ не отличается активностью. Арская ЦБС решила позаимствовать опыт Российской государственной библиотеки: «Мы работаем не для молодежи, а с молодежью», тем самым вовлекая молодых непосредственно в деятельность библиотеки.

Молодые пользователи от 15 до 35 лет в библиотеках системы составляют 37 процентов от общего числа пользователей: это учащиеся, студенты, молодые специалисты, рабочие. В городе осуществляют свою деятельность семь школ и три колледжа: педагогический, гуманитарно-технический и аграрный, где обучается молодежь также из других районов республики.

Для подростков и молодежи в библиотеках работают клубы «До 16 и старше», клуб молодого избирателя «Горизонт», «Туган ягым – яшел бишек», «Тылсым». На обсуждения, дискуссии приглашаются партнеры из центра «ФОРПОСТ», отдела по делам детей и молодежи, военного комиссариата. Деловая игра «Мы выбираем будущее страны», информационный час «Конституция – основной закон нашей страны», правовой тренинг «Знать закон…» проходят с участием представителей местного отделения партии «Единая Россия».

На эстафете передового опыта «Собственный бизнес – средство от кризиса» подростки встретились с успешными предпринимателями района, интересовались тонкостями предпринимательской деятельности, предлагали свои бизнес-проекты и вместе их обсуждали.



*Гульназ Камалова*



*Деловая игра «Мы выбираем будущее страны»*



*Музыкальный лекторий «Классика на все времена»*



*Литературный марафон в стенах кофейни Date&coffee*

На районном молодежном форуме состоялась презентация книжной выставки «Книга. Молодость. Успех». Увлеченные поэзией студенты вместе с библиотекарями читали стихи, приняли участие в анкетировании, высказали свое отношение к библиотеке. Любимым местом в библиотеке молодежь назвала фотозону со словом «УКЫ» (Читай), выстроенным из книг.

Библиотеки Арского района занимают достойное место в культурном пространстве города и села, а инновационные проекты являются одной из важнейших составляющих их деятельности. Такие усовершенствования, новые технологии, оригинальные идеи создают условия для достижения высоких результатов, в том числе для поддержания интереса к чтению, повышения общественной значимости книги.

В последние годы библиотеки сталкиваются с проблемой молодежного чтения, ведут поиск оригинальных решений. Один из вариантов – Литературный марафон в стенах кофейни *Date&coffee*. Литературные вечера проходят здесь в непринуждённой обстановке, участники делятся своими авторскими стихотворениями, читают произведения классиков, современных поэтов. Такие мероприятия позволяют активизировать читательскую и творческую деятельность молодых, повышают престиж библиотеки и книги в молодежной среде, делают чтение более привлекательным. Проект был удостоен премии Министерства культуры РТ «Творческий поиск».

Учитывая запросы молодежной аудитории, в 2019 году был разработан и представлен на соискание гранта Правительства Республики Татарстан проект #Өчпочмак, состоящий из трех блоков: библиотека, книга, молодежь. В рамках проекта предполагается организация современного библиотечного пространства – «зоны комфорта» для молодежи, организация Совета молодежи библиотеки, подготовка и проведение мероприятий, формирование волонтерского движения.

Сегодня библиотекам необходимо быть «на одной волне» с молодыми читателями, удовлетворять их потребности, создавать необходимые комфортные условия. Только в этом случае библиотека сможет популяризировать чтение и расширить читательскую аудиторию. Будущее – это Мы! ■

*Китапханәләрдә яшьләр белән эшләү елдан-ел яңа төсмерләр ала. Бу – замана таләбе. Алар белән «бер дулкында» яшәгәндә генә без бүгенге яшьләрне китапханәгә җәлеп итә алачакбыз. Мәкаләдә Арча үзәкләштерелгән китапханәләр системасының яшьләр белән эшләү тәҗрибәсе яктыртыла. Китапханәдә төрле клублар бар, тормышта үз урынын тапкан кешеләр белән очрашулар еш оештырыла. Яшьләрнең теләкләрен истә тотып, Date&coffee кафесында әдәби марафон үткәрү проекты бик кызыклы алым булып тора. Китапханәләрдә уңайлы мохит тудыру максатыннан һәртөрле грантлар алу өчен яңа проектлар уйлап табу, конкурсларда катнашу да – мөһим эш юнәлешләренең берсе.*

*Любовь КАПРАЛОВА,*
*заведующая Городской библиотекой*

# Изучая – сохраняем

## ОПЫТ РАБОТЫ БИБЛИОТЕК МБУ «АРСКАЯ ЦБС» ПО ЭКОЛОГИЧЕСКОМУ ПРОСВЕЩЕНИЮ

«СОХРАНИМ природу», «Экология в опасности»… Как часто мы слышим эти слова и не задумываемся над их глубоким смыслом. В библиотеках Арской централизованной библиотечной системы ведется разносторонняя работа по экологическому просвещению населения: проводятся акции, конкурсы, оформляются буклеты, памятки...

С января по июнь 2019 года во всех библиотеках района прошла экологическая акция «Сдай батарейку, спаси ежику жизнь», (повторение) которая позволила собрать более 350 кг использованных батареек. Жители города и района активно включились в акцию. В подарок за батарейки библиотека дарила участникам закладки с описаниями книг, рекомендованных к прочтению. Такой формат работы позволил привлечь в библиотеку новых читателей.

10 октября в Центральной библиотеке состоялось торжественное подведение итогов экологического конкурса «Волшебные превращения». Основная идея конкурса – пропаганда бережного отношения к природе путем правильной утилизации и использования бытовых отходов. Были приглашены гости – представитель Министерства экологии и природных ресурсов РТ, специалист Северного террито-



*Любовь Капралова*

риального управления, сотрудники Государственного природного заказника «Ашит». Конкурс проходил в двух номинациях: оригинальный костюм литературного героя и самая креативная поделка. На начальном этапе организации конкурса были некоторые сомнения: «А будет ли это интересно нашим читателям?», «Кто захочет возиться со старыми бутылками, газетами?». Все сомнения были напрасны. Сколько интересных и полезных поделок можно изготовить из бросового материала! На конкурс поступило около 50 работ. Жюри предстояло выбрать среди них лучшие. Яркие павлины из пластиковых бутылок для украшения приусадебных участков, игрушки, вазы для оформления интерьера заслуживают особого внимания. А костюмы литературных героев, представленные на конкурс, были один лучше другого. Роскошный наряд Наташи Ростовой из старых газет – настоящее произведение искусства. Костюмы Красной шапочки из использованных пакетов, Снежной Королевы из дисков, Золушки из одноразовой посуды – каждый костюм своеобразен, раскрывает характер литературного героя, позволяет окунуться в сюжет произведения и призывает вновь его перечитать. За оригинальные идеи участникам конкурса были вручены памятные подарки и дипломы. Конкурс вдохновил участников на новые открытия. Библиотеки выразили желание развивать это направление как хорошую и добрую традицию.

Заслуживает внимания деятельность экологического клуба «ГЕО» при городской библиотеке. Здесь дети с раннего возраста учатся бережно относиться к природе, познают ее с помощью сказок и небылиц. Библиотекари работают над тем, чтобы научить маленького человека думать об окружающем мире, понять свое место на земле, видеть в окружающем мире прекрасное, научить ценить это.

За эти годы в клубе появились свои традиции: ежегодный экологический фестиваль, встречи с эко-



Платье Наташи Ростовой




Экологический конкурс «Волшебные превращения»




Экологическая акция «Сдай батарейку, спаси ежику жизнь»

логами и другими специалистами города, акции «Мы за чистый город», «Солнце, воздух, книга, Я…», экологические походы и праздники. Активно проходят литературные и спортивные соревнования-викторины. Часто на экологических уроках библиотекарь «превращается» в почтальона, который знакомит детей с журналами о животных. Радует, что участники мероприятий научились самостоятельно разрабатывать тематические проекты: были предложены проекты «Экологическое состояние различных микрорайонов города», «Арск – моя радость и боль», в которых раскрывались проблемы экологии Арского района.

Новой формой экологического просвещения стало проведение мероприятий на открытом воздухе. Во время походов к родникам, реке Казанке читатели наслаждаются красотой природы, чистым воздухом, пением птиц, разгадывают загадки и разучивают поговорки. Проходя по тропинкам родного края, изучают растения, говорят об их предназначении, читают стихи о природе, красоте родного края. В зимнее время года проводятся литературно-оздоровительные мероприятия «Зимняя сказка», «Мороз и солнце», «Масленичный разгуляй». Библиотекари стремятся приобщить детей к здоровому образу жизни, к занятиям спортом, к изготовлению кормушек для птиц.

Невозможно заставить людей любить и охранять природу, каждый человек должен сам прийти к осознанию величия, красоты и одновременно хрупкости природы, принять это как свою внутреннюю потребность. А библиотекари могут в этом помочь – объяснить, что охранять природу нужно не от человека, а для человека. ■

*«Табигатьне саклыйк», «Экологиягә куркыныч яный» – бу гыйбарәләрне еш ишетәбез һәм кайчагында аларның тирән мәгънәсе турында уйланмыйбыз. Әмма табигатьне саклау – гаять зур хезмәт, һәр кеше бу эш белән кызыксынырга тиеш. Арча үзәкләштерелгән китапханәләр системасы китапханәләрендә халыкка экологик белем бирү юнәлешендә күпкырлы эш алып барыла. Китап укучыларның экологик мәгълүматларын күбәйтүгә, бигрәк тә яшь буынның рухи дөньясын баетуга җитди игътибар бирелә: акцияләр, конкурслар үткәрелә, буклетлар, белешмәлекләр төзелә. «Батарейка тапшыр һәм керпенең гомерен сакла!» акциясе ярдәме белән 350 килограммнан артык кулланылган батарейкалар җыйналды. Мәкаләдә шулай ук китапханәдә узган «Тылсымлы үзгәрешләр» конкурсы, 1 номерлы шәһәр китапханәсе каршында эшләүче «ГЕО» клубы эшчәнлеге турында тулы мәгълүмат бирелгән.*

*Алсу РАХИМБАЕВА,*
*заведующая районной детской библиотекой*

# Творим добро сегодня

## ОСОБЕННОСТИ РАБОТЫ С ДЕТЬМИ-ИНВАЛИДАМИ

ВАЖНЕЙШИМ направлением деятельности библиотек района является работа с детьми-инвалидами. Библиотека ставит перед собой задачу помочь им адаптироваться в обществе, обеспечить развитие их творческих возможностей путем получения доступной информации, приобщения к культурной и духовной жизни.

Районная детская библиотека ведёт совместную работу с ГАУСО «Реабилитационный центр для детей и подростков с ограниченными возможностями здоровья Министерства труда, занятости и социальной защиты РТ «Исток надежды» в Арском муниципальном районе». Библиотекари проводят с детьми беседы о книгах, читают им сказки, стихи любимых писателей, организуют развлекательные мероприятия с элементами игры.

Тем, кто приходит в библиотеку в сопровождении родителей, библиотекари оказывают помощь в подборе литературы, проводят индивидуальные беседы с целью выявления их интересов и потребностей, приглашают посетить массовые мероприятия, посмотреть фильмы, мультфильмы в «Читальном кинозале». То есть стремятся вызвать у детей интерес к книге и любовь к искусству.

Ребята каждый раз встречают творческий коллектив библиотекарей с большим восторгом и искренней радостью. На одной из встреч ребята совершили увлекательное путешествие «По страницам любимых сказок», приняли активное участие в конкурсной программе вместе со сказочником Оле-Лукойе, литературными героями Пеппи Длинный Чулок и Незнайкой. Веселые конкурсы, игры, танцы, вкусные угощения и памятные подарки пришлись по душе не только детям, но и родителям, воспитателям. Завершилась игра-путешествие на дружеской ноте – сказочные герои и дети обменялись на прощание теплыми объятиями и продемонстрировали флэш-моб. Такая форма общения «ребёнок – книга – сказка» дарит юному читателю не только радость, но и несет много познавательных моментов.



*Алсу Рахимбаева*

Своих особенных читателей библиотекари частенько знакомят с книгами известных детских писателей. По творчеству самого весёлого писателя Виктора Драгунского проводился литературный праздник «Друг детства». Его знаменитую книгу «Денискины рассказы» чи-





*Литературный праздник «Друг детства»*





Мастер-класс по скрапбукингу

тают уже больше полувека, она пользуется успехом по сей день. Сам В. Драгунский, хотя и прожил нелегкую жизнь, никогда не унывал, мечтал работать в цирке «Рыжим клоуном» и смешить детей. Желание не исполнилось, но он начал писать сценарии для клоунов. Опираясь на тексты В. Драгунского, для особенных читателей библиотекари устроили самое настоящее цирковое представление. Вместе с клоунами Ириской и Карамелькой ребята играли, веселились, демонстрировали свои знания.

В литературном ринге «Сказочное Лукоморье», посвященном Пушкинскому дню в России, дети в игровой форме совершили путешествие по удивительным сказкам А. С. Пушкина, прошли испытания ученого кота, разгадали сказочные кроссворды, загадки. Брейн-ринг завершился просмотром мультфильма «Сказка о попе и о работнике его Балде», снятого по мотивам одноименной сказки А. С. Пушкина.

Час веселых затей «Мы с любимой детской книжкой неразлучные друзья» прошел с героями Веселинкой и Смайликом. Главная цель мероприятия, посвященного Международному дню детской книги, – создать праздничное настроение и раскрыть творческие способности детей. Юные читатели приняли участие во всевозможных конкурсах, играх, викторинах, в ходе которых ребят ждали занимательные, поучительные и нескучные вопросы. Они испытали и свои интеллектуальные возможности в литературном конкурсе: вспоминали прочитанные книги, отгадывали имена героев, отвечали на вопросы беспроигрышной лотереи.

В рамках реализации республиканского проекта «Сможем вместе» прошла познавательная игра «Все профессии важны!» и мастер-класс по скрапбукингу «Большой подарок для мамы». Мероприятия в цикле «Мои способности – мои возможности» особенно понравились детям тем, что они, используя различные поделочные инструменты, смогли изготовить авторские открытки для своих любимых мам. Открытки получились яркими, оригинальными.

«Кто умеет приносить небольшую пользу, тот уже может сделать много добра!» – писал Ф. Достоевский. Юные читатели районной детской библиотеки приняли участие в акции «Делаем добро вместе»: принесли книги для своих особенных сверстников. Реабилитационному центру были подарены 72 книги в красивых переплётах. Нужно было видеть лица детей, не скрывающих восторга, когда они перелистывали книги разглядывали картинки.

Детская библиотека является площадкой, позволяющей ребенку чувствовать себя свободным и равноценным. Работа с детьми-инвалидами способствует преодолению физического недуга, реабилитации, полноценной интеграции в общество. Работа в этом направлении требует от библиотекарей дополнительных компетенций. Для выстраивания доверительных отношений необходимы большие запасы доброты и сердечности. Только в этом случае всё работа непременно приведёт к успеху. ■

*Инвалид балалар белән эшләү – район китапханәләре эшчәнлегендә мөһим юнәлешләрнең берсе.*

*Район балалар китапханәсе Арча муниципаль районындагы мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Исток надежды» реабилитация үзәге» социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе белән хезмәттәшлек итә. Китапханәчеләр мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән китаплар турында әңгәмәләр үткәрәләр, яраткан язучыларының әкиятләрен, шигырьләрен укыйлар һәм төрле уеннар, күңел ачу кичәләре оештыралар. Мондый чараларда катнашу балаларга үзләренең иҗади мөмкинлекләрен ачарга, аралашырга һәм җәмгыять тормышына җайлашырга ярдәм итә.*

*Рузия ХАКИМОВА,*
*библиотекарь методико-библиографического отдела Центральной библиотеки*

# Информационные технологии в условиях современной библиотеки

ИНФОРМАЦИОННЫЕ технологии играют ключевую роль в процессах получения, накопления и распространения информации, новых знаний, являются одним из важнейших инструментов развития библиотек.

В настоящее время 57 библиотек муниципального бюджетного учреждения «Арская централизованная библиотечная система» компьютеризованы и подключены к сети Интернет.

Для каждой библиотеки заведен официальный почтовый ящик в домене tatar.ru и установлена коммуникационная программа – клиент MicrosoftLync. В настоящее время все библиотеки работают в этой системе. Внедрение программы намного облегчило работу. Снизились затраты на проведение обучения, междугородних переговоров. Система обеспечивает удобную и эффективную среду взаимодействия и совместной работы, позволяет дистанционно решать текущие проблемы сельских библиотек. Не менее одного раза в месяц проводятся совещания в режиме видеоконференции.



*Рузия Хакимова*



*Работа с сельскими филиалами по программе Microsoft Lync*

Пользователи библиотек имеют возможность бесплатно пользоваться услугами сети Интернет. В Центральной библиотеке функционируют автоматизированные рабочие места пользователей, которые обеспечивают доступ в Интернет, позволяют пользователям самостоятельно работать на компьютере: набирать текст, просматривать фото- и видеоматериалы, записывать информацию на различные носители.

Несколько лет пользователи Арской Центральной библиотеки имеют бесплатный доступ к справочно-правовой системе «Консультант Плюс», которая обеспечивает

быстрый поиск законодательных и нормативных актов по определенным запросам. На сегодняшний день услугами «Консультант плюс» воспользовались 350 человек, среди которых студенты, люди старшего возраста и др.

Используя информационные технологии, библиотекари Центральной библиотеки практикуют следующие формы работы по привлечению читателей: виртуальные выставки, медиа-уроки, буктрейлеры; оформляются пособия малых форм: буклеты, памятки, закладки. Их количество растет, улучшается и качество их исполнения.




*Сайт Центральной библиотеки на портале Национальной электронной библиотеки РТ (kitap.tatar.ru)*

Важнейшим результатом информатизации библиотек являются сайты, на которых предоставляется информация о библиотечных услугах. Сайт Центральной библиотеки и ее филиалов представлен на портале Национальной электронной библиотеки РТ (kitap.tatar.ru). Работа библиотек освещается на двух государственных языках. На сайте библиотеки представлена общая информация, новости, конкурсы.

Деятельность библиотек широко представлена и в социальных сетях: «ВКонтакте» (более 7000 пользователей), Instagram (более 1900 подписчиков), что позволяет оперативно информировать удаленных пользователей о работе библиотеки, а также осуществлять справочно-консультационную поддержку и обратную связь в виде комментариев, предложений.

Библиотеками МБУ «Арская ЦБС» ведется работа по выдаче единого читательского билета (ЕЧБ), сохраняя при этом традиционный формуляр пользователя. На сегодняшний день выдано около 4 тысяч ЕЧБ по всему району. ЕЧБ выдается пользователю бесплатно. Пользователь получает логин и пароль к личному кабинету на портале «Национальная электронная библиотека Республики Татарстан» (*kitap.tatar.ru*) и бесплатный *Wi-fi* в библиотеке.

В текущем году Центральная библиотека подключилась к Национальной электронной библиотеке РФ, заключив договор с ФГБУ «Российская государственная библиотека» (Москва). Библиотека получила возможность использовать фонды крупнейших библиотек России, создавать тематические подборки электронных копий изданий единого фонда НЭБ РФ и осуществлять информационное обслуживание пользователей в новом формате. ■



*Наши активные читатели*

*Хәзерге заман китапханәсен яңа мәгълүмати технологияләр кулланып эшләүдән башка күз алдына да китереп булмый. Заманча эш алымнары бик күп төрле һәм алар китап укучылар алдында зур мөмкинлекләр ача. Мәкалә «Арча үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет учреждениесе эшчәнлегендә компьютер технологияләреннән файдалану тәҗрибәсен яктырта.*

*Гульгена ХАСАНОВА,*
*заведующая отделом комплектования*
*и обработки литературы*

# Традиции и новации в работе отдела комплектования

С ОТДЕЛА комплектования и обработки литературы начинается путь книги в библиотечном фонде: определяется ее место на полке, присваивается индивидуальный номер, по которому отслеживается судьба каждого экземпляра. Традиционное понятие «комплектование библиотечных фондов» меняет свое содержание, становясь важной составляющей информационного обеспечения пользователей.

Отделу комплектования и обработки литературы Арской ЦБС важно определить, какие издания представляют наибольший интерес для пользователей, в каком формате и какие печатные издания в перспективе могут быть приобретены.

Фонд Арской Центральной библиотеки формируется на основе печатных и аудиовизуальных носителей информации. На сегодняшний день библиотечный фонд составляет 488 262 экземпляра книг, брошюр, периодических изданий и аудиовизуальных документов. Ежегодно в библиотеку поступает более 12 000 изданий. Основными источниками комплектования фондов являются Татарское книжное издательство, Национальная библиотека РТ и местный бюджет Арского муниципального района. Для оптимального соответствия запросам населения необходимо качественное обновление фондов.



*Гульгена Хасанова*

В этом случае на помощь приходят спонсоры, местные писатели, администрация района и читатели. Последние три года отдел комплектования проводит акцию «Подари книгу любимой библиотеке», в результате которой в библиотеку поступило более 9 000 экземпляров книг.

Нельзя сказать, что потребность ЦБС в актуальной литературе удовлетворяется полностью. Библиотека нуждается в лучших произведениях современной художественной и детской литературы. В целях обеспечения сельских филиалов изданиями, пользующимися наибольшим спросом среди читателей, в 2019 году был организован обмен книгами «Бук-ринг»: книжные комплекты переходят из одного филиала в другой в порядке очереди.

Наибольшим спросом пользуются детские книги и литература по школьной программе. Каждое лето огромное количество детей со списком книг для внеклассного чтения обращается в районную детскую библиотеку. Библиотека удовлетворяет запросы не только своих читателей, но и учащихся, приехавших на летние каникулы из других городов. При комплектовании фондов литература по школьной программе всегда в приоритете.

Для полноценного комплектования фондов нельзя оставлять без внимания и периодику. Периодические издания могут обеспечить библиотекам до 40 % книговыдачи. Спрос на журналы высок и в селах, и в городе. В последние годы читатели особенно часто интересуются изданиями по приусадебному и домашнему хозяйству, здоровому образу жизни, востребованы журналы для женщин и детей.

Не секрет, что библиотека сможет наиболее полно удовлетворять читательский спрос лишь при условии грамотно и качественно сформированного книжного фонда. При этом немаловажную роль играет своевременное очищение фондов от устаревшей по содержанию и ветхой литературы. Библиотека активно занимается изучением



Новые формы списания книг – практикум для библиотекарей



Обучение сельских библиотекарей

фондов и исключением невостребованных читателями книг.

«Библиотеки – это сокровищницы всех богатств человеческого духа», – сказал выдающийся немецкий философ и математик Готфрид Вильгельм Лейбниц. Деятельность по сохранению книжных фондов является одной из важнейших в работе библиотеки. С этой целью в феврале 2019 года отделом комплектования и обработки литературы был проведен семинар «Библиотечные фонды. Правила формирования и обеспечение сохранности».

С целью формирования бережного отношения к книге каждый год проводится конкурс «Вечная спутница книги», сельские филиалы проводят конкурс по организации оригинального Дня периодики «Журнальное ассорти».



Новая партия книг порадует читателей сельских библиотек

Работа отдела не ограничивается обработкой новых книг и их списанием. Сотрудники регулярно оказывают методическую помощь сельским филиалам в ведении учетных документов библиотечного фонда, каталогов библиотеки и картотек. В текущем году были проведены практикумы «Списание, обработка акта, технология списания. Формирование акта списания», «Ведение и оформление каталогов и картотек» и др.

XXI век – век информации, высоких компьютерных технологий. С 2001 года в Арской ЦБС функционирует электронный каталог в программе «МАРК». С 2013 года библиотека участвует в пилотном проекте по внедрению АБИС «Руслан». Создание электронного каталога позволило организовать работу отдела комплектования и обработки литературы на качественно новом уровне. На сегодняшний день в электронный каталог занесено более 42 000 библиографических записей: вместе с вновь поступившими изданиями сотрудники занимаются введением ретрокниг. Таким образом, в электронном каталоге удалось отразить документы Центральной библиотеки и нескольких сельских филиалов. Списание документов также происходит через электронный каталог. Оформление ежегодной подписки на периодические издания через данную программу значительно облегчило работу сотрудников библиотеки.

Поисковые возможности электронного каталога в большой степени зависят от компетентности, наличия широкого кругозора, трудолюбия и ответственности систематизатора, его желания как можно полнее отразить имеющуюся литературу. Сотрудники отдела повышают свою квалификацию на специальных курсах по работе с электронными каталогами в программе АБИС «Руслан».

Арская ЦБС – одна из передовых библиотечных систем республики. Для обмена опытом и изучения программы «Руслан» в район приезжают коллеги из субъектов РФ. Оперативность и качество работы отдела комплектования помогают сократить путь книги к читателю, порадовать его литературными новинками, получить информацию о необходимом ему издании в справочно-поисковом аппарате библиотеки. ■

*Арча үзәкләштерелгән китапханәләр системасы 2013 елдан «Руслан» автоматлаштырылган китапханә-мәгълүмат системасының сынау проектында катнаша. Әлеге программа китапханәләргә зур мөмкинлекләр бирде. Тәҗрибә уртаклашу өчен Арчага күрше район китапханәләреннән, хәтта чит төбәкләрдән дә киләләр. Төп бурыч – мәгълүмат эзләү эшенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм китап укучыларны кыска вакыт эчендә кирәкле басмалар белән тәэмин итү.*

• СЕЛЬСКИЕ БИБЛИОТЕКИ АРСКОГО РАЙОНА
• АРЧА РАЙОНЫНЫҢ АВЫЛ КИТАПХАНӘЛӘРЕ

*Рузилә ӘҮХӘДИЕВА,*
*Казанбаш авылы китапханәчесе*

# Тормыш яме – яшәүдә, яшәү яме – гаиләдә

ҺӘРКЕМГӘ кайтып сыенырлык нигез, гаилә кирәк. Ни генә булмасын, кеше гаиләдә ял итә, рухи көч җыя, күңел җәрәхәтләрен дәвалый. Тату, дус, бердәм гаиләләр генә ыру-нәселебезнең абруен арттыра, сәламәт тормыш нигезен тәшкил итә.

Казанбаш авылы китапханәсе эшчәнлегенең төп юнәлеше – гаиләләр белән эшләү. Өлкәннәрнең балалары белән бергәләп китапханәнең даими кунаклары булулары күңелне сөендерә. Алар өчен китап фондының бер өлеше «Гаилә – бәхет ачкычы» исеме астында тупланган һәм «Гаилә: син + мин», «Бала тәрбияләү», «Хуҗага һәм хуҗабикәгә» дигән темаларга аерып куелган. Моннан тыш, «Әни йорты оҗмахтыр», «Әтиләр сүзе – акылның үзе», «Өйнең яме бала белән» исемле тематик папкаларга газета-журналларда басылып чыккан мәкаләләр җыелып бара. «Ватаным Татарстан» газетасының җомга саны кушымтасын да аерым туплап барып, андагы киңәшләрне китап укучыларыбызга даими рәвештә тәкъдим итәбез. Шунда ук «Гаилә – тормыш терәге» исемле картотека да урын алган. Анда гаилә проблемаларын яктыртучы вакытлы матбугат мәкаләләре, гаилә бәйрәмнәре сценарийлары басылган газета-журналлар күрсәтелә.

Гаиләләрнең буш вакытларын күңелле, файдалы итеп үткәрү һәм буыннар бәйләнешен ныгыту максатыннан китапханәдә һәм авыл мәдәният йортында гаилә бәйрәмнәре, бәйгеләр уздырыла. Озак еллар бергә яшәгән үрнәк гаиләләр белән уздырылган «Пар канат җылысы» исемле очрашу кичәсен авыл халкы бик яратып кабул итте. Бу кичәдә тормыш юлыннан иңне-иңгә куеп атлаучы гаиләләр, яшь буынга үзләренең татулыкта яшәү серләрен җиткерделәр. «Шәҗәрә ул – үткәннәрдән киләчәккә тәрәзә» исемле тарихи-әдәби сәяхәтнең дә төп эчтәлеге – буыннар бәйләнеше булды.

Һәр гаилә – үзе бер серле сандык ул. Ата – улын, ана кызын тормыш нечкәлекләрен аңларга өйрәтә. Тату гаиләдә тәрбияләнгән бала, аның җылысын саклап, сүндермичә киләчәктә бәхетле оя булдырачак. Ә андый гаилә төзү җиңел гамәлләрдән түгел. Моның өчен бик нык тырышырга, башкаларның тәҗрибәләрен өйрәнергә кирәк. Китапханәдә уздырылган чараларда без шуларны күз алдында тотабыз. «Гаиләм – минем терәгем», «Яшәүнең иң олы мәгънәсе – гаилә җылысын



*Рузилә Әүхәдиева*



*Әдәби кичә «Гаилә – ул җылы учак»*

саклауда», «Гаилә – ул җылы учак», «Гаилә – бәхет ачкычы», «Оясында ни күрсә, очканында шул булыр» кебек китап күргәзмәләре һәм аларга ясалган күзәтүләр тормыш тәҗрибәсен тулыландыра.

Ә инде «Бәхетебез тора икебездән», «Пар канатта гына икән яшәү көче», «Башваткыч», «Иң күркәм гаилә» кебек бәйрәмнәрдә без авылдашларыбызның күркәм гаилә традицияләре үрнәкләре белән танышабыз.

Яшүсмерләр белән исә гаилә турында «Барысы да мәхәббәттән башлана», «Мәхәббәт – ул үзе иске нәрсә...», «Өе барның – кое бар» кебек диспутларда, белешмә-мәгълүмат сәгатьләрендә фикер алышабыз. Гашыйклар көне уңаеннан уздырылган бәйрәмнәрдә төрле бәйгеләр, уеннар оештырабыз. Шулай ук «Ягез әле, әтиләр!», «Ягез әле, әниләр!», Әниләр белән могҗизалар кыры, «Гаҗәеп әби», «Әбекәй-алтыным» кебек ярышлар да еш уздырыла. Мондый чаралар гаиләләрне, авылдашларны аралашуга чакырырга, ялларын күңелле итеп оештырырга ярдәм итә. Гомумән, безнең барлык чараларыбыз да китапка мәхәббәт һәм сакчыл караш тәрбияли, бер-береңә игътибарлы һәм китап белән дус булырга өнди.

Гаилә кыйммәтләре җәмгыятьтә һәрвакыт иң мөһимнәрдән санала. Шуңа күрә дә гаиләләр белән эшләү кызыклы да, мавыктыргыч һәм кирәкле дә, шул ук вакытта катлаулы да юнәлешләрнең берсе. Китапханә белән гаиләнең хезмәттәшлек итүе яшь буынны тәрбияләүдә әти-әниләргә ярдәмче генә түгел, ә ышанычлы дус булуы өчен бөтен мөмкинлекләрне дә кулланып эшләргә тырышабыз. ■

*Одно из важнейших направлений деятельности Казанбашской сельской библиотеки – работа с семьями. Понимание важности семьи в жизни общества, ее роли в воспитании новых поколений, объединение усилий библиотеки, школы и других организаций в формировании культуры семейных отношений – такие важные задачи решает сегодня сельская библиотека. Конкурсы «А ну-ка, папы», «А ну-ка, мамы», «Супер бабушка» позволяют сплотить семью, организовать полезный досуг односельчан, пробудить интерес к книге и чтению. Систематически пополняются тематические папки-дайджесты, ведётся картотека газетно-журнальных статей по проблемам воспитания и семейных традициях*

# Без – Тукайлы халык!

*«... мин кулыма китап алам,*
*Аның изге сәхифәләрен актарам.»*
Габдулла Тукай. «Китап», 1909 ел

БӨЕК Тукаебызның «Китап» исемле шигыре дөнья күргәнгә инде 110 ел үтеп киткән. Ул еллардан соң заманалар ничә тапкыр чуалгандыр, дөньялар ничә тапкыр үзгәргәндер, тормышның авыр йөген халык җилкәсе күпме күтәрә алгандыр? Әмма татар халкы китапсыз яши алмады, китапка-рухи азыгына тартылды. Китапханәгә укучылар сукмагы өзелми һәм моннан соң да укучыларыбыз кимемәс дип ышанам.




Наилә Әхмәтҗанова

Яңа Кырлай авылы китапханәсенең бай тарихы бар. Тарих битләрен ача башлау белән, авылыбызның изге Тукай җире булуын әйтмичә мөмкин түгел. Ничек инде Тукайны сыендырган, аңа иҗат дәрте биргән халык аң-белемгә тартылмасын, үзенең мәдәниятен үстермәсен?! Тарихка күз салсак, колхозлашуның беренче елларында ук белемгә омтылыш күзгә ташлана. Китапханәнең тарихы авылыбыз тарихы белән, бөек Тукаебыз исеме белән бергә үрелеп бара.

Бүген Яңа Кырлай авылы китапханәсе Яңа Кырлай, Яңа Иябаш авыллары халкына хезмәт күрсәтә. 2018

***Наилә ӘХМӘТҖАНОВА,***
*Яңа Кырлай авылы китапханәсе мөдире*



*Язучылар белән очрашу*



*Тукай паркында әдәби геройлар белән*

нче ел нәтиҗәләреннән күренгәнчә, китапханәнең 900 гә якын китап укучысы бар.

Яңа Кырлай авылы китапханәсе Тукай рухын саклаучы гына түгел, ә яшь буынга, җөмһүриятебез халкына, авылыбызга Бөек Тукаебыз эзләре белән танышу өчен килгән кунакларга мәгълүмат бирүче мәдәни-мәгълүмати үзәк буларак хезмәт күрсәтә. Биредәге бер генә чара да Габдулла Тукай шигырьләреннән башка узмый. Китапханәдә Г.Тукайның иҗатын тирәнтен өйрәнү, аның шәхесе нигезендә яшь буынны тәрбияләү юнәлешендә даими эш алып барыла. «Без Тукайны яхшы беләбезме?» дигән уен-викторина, «Шагыйрь үткән сукмаклар буйлап» исемле әдәби кичә, «Тукайдан илһам алып» дигән баш астында иҗади бәйгеләр һәм башка чаралар уза. «Музей һәм балалар» атналыгы кысаларында «Горурлыгыбыз – Тукай» исемле әдәби кичә, Габдулла Тукай мирасын өйрәнүгә багышланган «Без – Тукайлы халык» Республикакүләм Габдулла Тукай укулары, «Сөйкемле Шүрәле» бәйгесе оештырыла. Әлеге чаралар Мәдәният хезмәткәрләре, мәктәп, балалар бакчасы, музей коллективы белән берлектә эшләнә.

Милләтебезне дөньяга таныткан шагыйребезнең әсәрләрен авылыбызда һәркем кечкенәдән күңеленә сеңдереп үсә, хәтта яттан белә. 26 апрель – безнең өчен иң матур бәйрәмнәрнең берсе. Һәр елны Яңа Кырлайга Габдулла Тукайның туган көне уңаеннан язучылар, артистлар, Г.Тукай премиясе лауреатлары килә. Мәртәбәле кунаклар белән очрашуны, аралашуны һәркем көтеп ала.

Соңгы елларда китапханә эшчәнлегендә мәгълүмати технологияләр куллану бик күп мөмкинлекләр ачты. Бу үз чиратында, китапханәчеләргә таләпләрне үзгәртте. Укучыларыбызның сорауларына тулы җавап бирү өчен, Интернет челтәренә дә мөрәҗәгать итәбез. Уздырган чаралар турында һәр яңалык китапханә сайтына урнаштырып барыла.

2019 ел безнең өчен уңышлы ел булды. Иң истә калган, куанычлы вакыйга – «Муниципаль китапханәләрне модернизацияләү» федераль программасы кысаларында Яңа Кырлай китапханәсен заманча үзгәртү өчен 5 миллион сум күләмендә грант оту. Киләчәктә китапханә тамырдан үзгәрер. Укучылар өчен яңа мөмкинлекләр булдырылыр һәм китап укучыларыбыз тагын да артыр дип ышанабыз.

Оба издания просуществовали недолго. Всего было подготовлено три номера «Журнала Библиотеки Академии наук УССР» и один выпуск «Научного сборника Библиотеки АН УССР». Журнал был изготовлен на стеклографе Академии наук УССР в количестве 40 экз., а тираж сборника планировался в количестве 1500+115 экз. К сожалению, ещё на выходе из типографии издание было резко раскритиковано за якобы националистический уклон, и весь его тираж был запрещён. Директор Библиотеки Ю. Меженко был уволен с работы. По сути, украинские учёные были наказаны за попытку продолжить создание национального библиографического репертуара книги.

Несколько комплектов «Журнала Библиотеки Академии наук УССР» хранятся в читальном зале библиотековедческой литературы Института библиотековедения НБУВ. Сохранившиеся отдельные экземпляры сборника также хранятся в НБУВ: один с вырезанными страницами статей Ю. Меженка в читальном зале библиотековедческой литературы, второй сохранился полностью как архивный экземпляр и имеет статус документа фонда ограниченного пользования, ещё несколько экземпляров хранятся в обменно-резервном фонде НБУВ.

Издания, которые должны были бы засвидетельствовать послевоенное возрождение украинской

библиотечной мысли, фактически были разгромлены. Опубликованные в них материалы и сегодня остаются ценным источником для научных исследований, а обнародованные идеи продолжают быть актуальными.

Только в период обретения страной независимости Национальная библиотека Украины имени В. И. Вернадского смогла возродить практику подготовки и выпуска специализированных научных изданий. Сегодня Библиотека издаёт научно-теоретический и практический журнал «Библиотечный вестник» («Бібліотечний вісник») (с 1993 года), реферативный журнал «Джерело» (с 1999 года), ряд сборников научных трудов: «Рукописное и книжное наследие Украины» («Рукописна та книжкова спадщина України») (с 1993 года), «Украинская биографистика» («Українська біографістика») (с 1996 года), «Научные труды Национальной библиотеки Украины имени В. И. Вернадского» («Наукові праці Національної бібліотеки України імені В. І. Вернадського») (с 1998 года), «Славянские горизонты» («Слов'янські обрії») (с 2006 года) [9]. В рамках международного сотрудничества готовится научно-практический и теоретический сборник «Библиотеки национальных академий наук: проблемы функционирования, тенденции развития» (Libraries of national academies of sciences: problems of functioning, tendencies of development). Авторами выступают специалисты не только НБУВ, но и талантливые учёные и исследователи из других библиотек и научных учреждений как Украины, так и стран ближнего и дальнего зарубежья. Такое сотрудничество свидетельствует о возрождении школы украинского библиотековедения, книговедения и библиографии, а традиции тех лет продолжаются и развиваются на новой интеллектуальной базе.

### *Литература*


*1. Книжний вісник // Електронна бібліотека «Україніка» [Електронний ресурс]. – Режим доступа: http://irbis-nbuv.gov.ua/ulib/item/UKR0009560;*

*2. Бібліотечний журнал // Електронна бібліотека «Україніка» [Електронний ресурс]. – Режим доступа :http://irbis-nbuv.gov.ua/ulib/item/UKR0009564;*

*3. Солонська, Н. Періодичні видання Національної бібліотеки України (1919–1998) / Н. Г. Солонська // Бібліотечний вісник. – 1998. – № 5. – С. 38–49;*

*4. Масловська, С. Журнал бібліотекознавства та бібліографії / С. М. Масловська, Л. А. Поперечна // Українська бібліотечна енциклопедія [Електронний ресурс]. – Режим доступа: http://ube.nplu.org/article/;*

*5. Стрішенець, Н. Меженко Юрій Олексійович / Н. В. Стрішенець // Українська бібліотечна енциклопедія [Електронний ресурс]. – Режим доступа : http://ube.nplu.org/article/;*

*6. Юрій Олексійович Меженко (1892–1969): матеріали до біографії / НАН України; ЦНБ ім. В.І.Вернадського / ред. О. С. Онищенко; сост. Т. А. Ігнатова, Н. В. Козакова, Н. В. Стрішенець. – Київ, 1994. – 175 с. – (Науково-довідкові видання з історії України; Вип. 31).*

*7. Сокур, О. Журнал Бібліотеки Академії наук УРСР // Електронна бібліотека «Україніка» [Електронний ресурс]. – Режим доступа: http://irbis-nbuv.gov.ua/ulib/item/UKR0005698;*

*8. Сокур, О. Науковий збірник Бібліотеки АН УРСР / О. Л. Сокур // Українська бібліотечна енциклопедія [Електронний ресурс]. – Режим доступа: http://ube.nplu.org/article/;*

*9. Видавнича діяльність Національної бібліотеки України імені В. І. Вернадського [Електронний ресурс]. – Режим доступа: http://www.nbuv.gov.ua/node/3742*



*2018 елда Украинаның В. И. Вернадский исемендәге Милли китапханәсе үзенең 100 еллык юбилеен билгеләп үтте. Илдәге әлеге зур китапханәнең бер гасырлык тарихында берничә мәртәбә аның җирлегендә һәм көче белән китапханә эшенә багышланган бөтенукраина матбугат басмасы барлыкка китерү һәм бастырып чыгару омтылышлары ясала. Мәкаләдә һөнәри китапханә журналлары һәм җыентыклары оештыру һәм нәшер итү тәҗрибәсе тасвирлана. Аларда дөнья күргән материалларның бүген дә фәнни эзләнүләр алып бару өчен кыйммәтле чыганак булуы, күп идеяләрнең һәм теорияләрнең әле дә әһәмиятен югалтмавы ассызыклана.*

*Ирек ҺАДИЕВ,*
*Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең фәнни һәм методик эшләр буенча директор урынбасары*

# «Таҗетдин Ялчыгол» китабы



## ШӘХЕСНЕ ҺӘМ АНЫҢ ИҖАДИ МИРАСЫН ӨЙРӘНҮ ЮЛЫНДА ӘҺӘМИЯТЛЕ АДЫМ

«КИЛЕР заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын энәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле», – дип язган бөек шагыйребез Габдулла Тукай. Әйе, андый заман килде. Онытылган һәм оныттырылган исемнәрне, шәхесләрне, аларның иҗатын соңгы берничә дистә ел дәвамында кабаттан халкыбызга кайтара башладык.

Шушы ният-максат белән әзерләнгән чираттагы китап – гомерен халкына хезмәттә үткәргән күренекле мәгърифәтче, галим, тарихчы, язучы, мөгаллим, дин эшлеклесе Таҗетдин Ялчыголга багышланган яңа тарихи-документаль җыентык та, ниһаять, быел басылып чыкты һәм китапханәләргә,



*Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә «Таҗетдин Ялчыгол» китабын тәкъдим итү кичәсеннән соң*

җәмәгатьчелеккә тарала башлады. Ул Татарстанның халык шагыйре, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев җитәкләгән «Җыен» фондының «Шәхесләребез» сериясендә мең ярым данә тираж белән дөнья күрде.

Китап Таҗетдин Ялчыголның киңкырлы эшчәнлегенә багышлана. Аңарда мәшһүр шәхеснең кайбер әсәрләре, аның турында мәкаләләр, документлар, күпсанлы фотосурәтләр урын алган. Китап татар халкының атаклы кешеләре һәм милли әдәбиятыбыз ядкярләре белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәгаенләнгән.

Тарихи-документаль җыентык Әсгать Сәфәров ярдәме белән нәшер ителде. Аның төзүчеләре – язучы Рөстәм Галиуллин белән Ирек Һадиев, фәнни мөхәррире – Җәүдәт Миңнуллин, бизәлеш мөхәррире – Рамил Миңнуллин, битләргә салучысы – Йолдыз Нуриева, каллиграфы – Әлфия Исхакова, корректоры – Ландыш Әүхәдиева, тышлыгын ясаучы рәссам – Григорий Эйдинов.

Кем ул Таҗетдин Ялчыгол? Аның турында элек тә, хәзер дә матбугатта мәгълүматлар чыгып тора. Ул Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдин кебек мәшһүр галимнәрнең игътибарыннан читтә калмаган. Әдәбиятчылардан Гали Рәхим, Газиз Гобәйдуллин аның




*Таҗетдин Ялчыгол – күренекле мәгърифәтче, галим, тарихчы, язучы, мөгаллим, дин эшлеклесе, табиб.*

Рушан Шәмсетдинов рәсеме. 1996 ел

иҗатын өйрәнгәннәр. Соңгы чорда Альберт Фәтхи, Миркасыйм Госманов, Хатыйп Миңнегулов, Марсель Әхмәтҗанов, Мәсгуть Гайнетдинов, Дамир Гарифуллин, Сәлим Гыйләҗетдинов, Ләйлә Шәмсетдинова хезмәтләрендә Таҗетдин Ялчыгол иҗаты чагылыш таба. Башкортстанда Әхнәф Харисов, Ишмөхәммәт Галәветдинов һәм башкалар аның хакында, әсәрләренең теле турында язып чыктылар.

Шулай да, Таҗетдин Ялчыгол турында беләбез диючеләргә караганда, «Кем соң ул? Исеме тарихта калырлык ниләр кылган?» – дип сораучылар күбрәк булыр. Шуңа күрә, гомерен халкына хезмәт итүгә багышлаган бу шәхес турында өстәмә материаллар эзләү һәм аларны өйрәнү, тупланган-өйрәнелгән кадәресен яңа басмалар, матбугаттагы мәкаләләр рәвешендә тагын да күбрәк сандагы укучыларга җиткерү, аның турында җае туры килгән саен сөйләп, мирасын һаман танытып тору дәвам итәргә тиеш. Таҗетдин Ялчыголның исемен мәңгеләштерүгә Зәй төбәгендә аеруча зур әһәмият бирелә. Зәйлеләр үзләренең озак еллардан бирле башкарып килә торган изге гамәлләре белән бу җәһәттән башкаларга менә дигән үрнәк!

Яңа китапның эчтәлегенә күз салыйк. Ул Татарстан Республикасы Президенты Аппараты җитәкчесе, әнисе ягыннан Таҗетдин Ялчыголның алтынчы буын оныгы Әсгать Сәфәровның «Киң колачлы шәхес» дигән кереш сүзе белән ачыла.

Алга таба филология фәннәре докторы Хатыйп ага Миңнегуловның Таҗетдин Ялчыгол тормыш юлын тасвирлаган, андагы гаять катлаулы һәм күп бәхәсләр тудыра торган фактларны бәян иткән, әсәрләренә этрафлы анализ ясаган, мирасына лаеклы бәя биргән күләмле мәкаләсе бирелә.

Таҗетдин Ялчыгол – тәрбияви, дини-әхлакый, тарихи, тел ягын-



*Таҗетдин Ялчыголның Коръәне*



*Ялчыгол Таҗетдин. Рисаләи Газизә шәрхе «Сөбател-гаҗизин». Кульязма. 1835 ел. Татарстан Республикасы Милли китапханәсе фондларыннан*



*Г. Таҗетдинов, А. Абдуллина, Н. Сәфәрова, Р. Вәлиев, С. Җиһаншина, Ф. Рәфыйков «Таҗетдин Ялчыгол» китабын тәкъдим итү кичәсеннән соң*

нан бай фәлсәфи әсәрләр иҗат иткән шәхес. Әлеге җыентыкта аның «Рисаләи Газизә» (басмага әзерләүчесе Хатыйп Миңнегулов), «Тәварихы Болгария» (басмага әзерләүчесе Сәлим Гыйләҗетдинов) әсәрләреннән саллы өзекләр урын алды. «Кырлай авылыннан Җаек (Уральски) каласына алырга килгәндә, мин ян тәрәзә төбендә «Рисаләи Газизә» укып утыра идем», – дип язып үтә Габдулла Тукай үзенең «Исемдә калганнар» әсәрендә.

Ә тагын да әүвәлрәк заманга, 1860 нчы елларга караган бер кулъязмада менә мондый юллар бар:

**Һәр китапларның арасында**
**Сөеп укыганым «Газизә».**
**Салкын йөзләрдин,**
**җаман сүздин**
**Бәнем җан гынаем да бик бизә.**

Әйе, татар халкында «Кыйссаи Йосыф» кебек үк яратып укылган китап булган ул – Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә»се. Әлеге әсәрнең төрле елларга караган күпсанлы басмалары, аның һәм «Тәварихы Болгария»нең кулъязма күчермәләре Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге фондларында да саклана. Алар китапханә хезмәткәрләре тарафыннан ел саен үткәрелә торган фәнни-археографик экспедицияләр вакытында һаман табыла тора.

Таҗетдин Ялчыгол шәхесен өйрәнүдә язучы, галим, Сарман районында яшәп иҗат итүче Дамир ага Гарифуллин күп көч куйды. Ул соңгы елларда архивтан тапкан документлар Таҗетдин Ялчыгол тормышындагы күп кенә билгесез сорауларга ачыклык кертте. Яңа китапта аның «Табышмаклы гомер иясе» дигән мәкаләсе тәкъдим ителде.

Китапка галимнәрдән Альберт Фәтхинең, Марсель Әхмәтҗановның, Мәсгуть Гайнетдиновның, Сәлим Гыйләҗетдиновның, Ләйлә Шәмсетдинованың, Резеда Маханованың, шулай ук танылган музыкант Шамил Монасыйповның, шагыйрә Рухия Ахунҗанованың мәкаләләре кертелде, алар Таҗетдин Ялчыгол иҗатының һәм эшчәнлегенең төрле якларын, ул калдырган мирасның әһәмиятен ачып күрсәтә.

Яшь язучы, хәзерге көндә «Казан утлары» һәм «Мәйдан» журналларының баш мөхәррире, «Таҗетдин Ялчыгол» китабының да төзүчеләреннән берсе Рөстәм Галиуллин Таҗетдин Ялчыгол турында «Васыять» дигән роман язды. Ул 2017 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты һәм укучылар тарафыннан яратып



*Ялчыгол Таҗетдин. Рисаләи Газизә шәрхе «Сөбател-гаҗизин». Кулъязма. 1844 ел. Татарстан Республикасы Милли китапханәсе фондларыннан*



*Ялчыгол Таҗетдин. Рисаләи Газизә шәрхе «Сөбател-гаҗизин». Кулъязма. XIX гасырның II яртысы. Татарстан Республикасы Милли китапханәсе фондларыннан*

кабул ителде. Яңа басмада бирелгән өзек, һичшиксез, романны тулаем укып карау теләген уятыр.

Китапта шулай ук Ризаэтдин Фәхретдиннең Тажетдин Ялчыголга багышланган белешмә язмасы, төрле чорларга караган берничә шигъри әсәр, шәхеснең тәрҗемәи хәленә кагылышлы архив документлары, шактый тулы библиография дә бар.

Милләттәшләремне китапханәләрдән бу китапны алып, җентекләп укырга, Тажетдин Ялчыгол, аның бай мирасы турында тагын да күбрәк мәгълүмат алырга, шулар белән яшь буынны да таныштырырга чакырам!

2019 елның 24 маенда Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Зур уку залында «Тажетдин Ялчыгол» дигән китапны киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү кичәсе булды. Кичәдә китапны басмага әзерләгән иҗат төркеме, галимнәр, мәгариф, мәдәният, дин әһелләре, язучылар, журналистлар, китап сөючеләр һәм Тажетдин Ялчыголның нәсел дәвамчылары – барлыгы 100дән артык кеше катнашты.

Китапханәгә җыелган халык алдында «Җыен» фонды рәисе Разил Вәлиев, Тажетдин Ялчыгол исемен халыкка кайтаруда зур өлеш керткән, исемнәре алда зурлап телгә алынган галимнәребез Хатыйп Миңнегулов һәм Дамир Гарифуллин, Татарстан Республикасының баш казые, күренекле дин эшлеклесе Җәлил хәзрәт Фазлыев, артистлар Зөһрә Сәхәбиева, Луара Шакирҗан, Әзһәр Шакиров, Илдус Әхмәтҗанов, Зәй районы Башкарма комитеты җитәкчесе Илнар Хафизов, Ялчыгол нәселе вәкиле Гамир Тажетдинов чыгыш ясадылар. Кичәнең олы кунагы Тажетдин Ялчыголның шәҗәрәсен булдыруда, аны тулыландыруда көчен, белемен кызганмыйча ихлас күңелдән тырышып йөрүче, нәсел дәвамчысы Нәкыя Фатыйх кызы Сәфәрова булды. Ул да катнашучыларга үзенең мәгънәле фикерләре белән мөрәҗәгать итте. Мөфти урынбасары Рөстәм хәзрәт Вәлиуллин Тажетдин Ялчыгол рухына багышлап дога кылдырды.

Китапханәнең Зур уку залы фойесында мәгърифәтченең китапханә фондларында саклanучы кульязма һәм басма китапларыннан торган һәм аның бай иҗади эшчәнлеген яктырткан басмаларны туплаган күргәзмә белән дә танышырга мөмкин булды.

Тажетдин Ялчыгол – татар халкы күңелендә тирән эз калдырган күренекле шәхес. Аның фәнни хезмәтләре милли мәдәниятебезнең алтын фондын тәшкил итә. Ул хезмәтләрне өйрәнү, саклау һәм шәхеснең исемен мәңгеләштерү – безнең изге бурычыбыз. ■



*Ялчыгол Тажетдин. Рисаләи Газизә шәрхе «Сөбател-гаҗизин». Казан, типо-литография наследников М. Чирковой, 1900 ел*




*Ялчыгол Тажетдин. Рисаләи Газизә. Казан, «Хозур» нәшрияты, 2014 ел*




*Ялчыгол Тажетдин. Тәварихы Болгария (Болгар тарихы). Казан, «Хозур–Тынычлык» нәшрият йорты, 2017 ел*

*В серии «Знаменитости» фонда «Җыен», который возглавляет видный общественный и политический деятель, писатель Разиль Валеев, вышел в свет историко-документальный сборник, посвященный Таджетдину Ялчыголу. 24 мая 2019 года в Национальной библиотеке Республики Татарстан состоялась презентация данного сборника. В мероприятии приняли участие ученые, деятели искусства, писатели, священнослужители, журналисты и широкий круг читателей, неравнодушных к национальному культурному наследию.*

*Флёра ГАРИПОВА,*
*Түбән Кама үзәкләштерелгән китапханәләр системасының Каенлы авылы китапханәчесе*

# Шәхесләребез белән бизәлә туган авылыбыз тарихы

КАЕНЛЫ авылы, Каенлы халкы тарих дулкыннарына кияреп, күп вакыйгаларны кичергән. Җир өчен авыллар арасындагы ызгышлар, революция вакытында, яисә колхозлашу елларында булган фаҗигале вакыйгалар, сугышлар – болар барысы да авылыбыз тарихында тирән эз калдырган. Әйе, авылыбызның үткәне тарихлы, данлы, хәзергесе кызыклы, киләчәге дә якты булыр дип ышанабыз.

Авылны анда яшәгән кешеләр, аларның кылган изге гамәлләре, аларның матур эшләре яшәтә. «Каенлы авылы тарихы»н туплап безгә мирас итеп калдырган Фәхри ага Шәрәфиев фаразлавынча, авылыбызның 400–450 еллык тарихы бар. «Казан ханлыгы яулап алынганнан, ягъни 1552 еллардан соң, корылык елларында Мамадыш районы Кече Сон авылыннан берничә гаилә килеп авылга нигез салалар», – дип яза ул. Шул еллар эчендә авылыбызда кемнәр генә яшәмәгән дә, кемнәр генә авылны яшәтү, танытуга көч куймаган. Һәр төбәкнең күренекле шәхесләре була. Алар турында горурланып сөйләнелә, кылган гамәлләре хөрмәтләнә, яшь буынны да шулар үрнәгендә тәрбияләү максаты куела. Без дә эшлибез бу юнәлештә. Мәдәният йортында «Шәхесләр белән бизәлә туган як тарихлары» дигән циклдан чираттагы чара үткәрелде. Бу юлы ул фәнни-гамәли конференция рәвешендә күренекле дин эшлеклесе, халык табибы, язучы һәм мәгърифәтче Таҗетдин Ялчыголга багышланды.



*Флёра Гарипова*



*Таҗетдин Ялчыголның нәсел дәвамчысы Гамир Таҗетдинов һәм китапханәче Флёра Гарипова Каенлыда узган конференция вакытында*

Әгәр дә авылыбызда, анда гына түгел, хәтта районыбызда туып-үскән яисә яшәгән күренекле шәхесләр исемлеген төзергә туры килсә, анда иң беренче булып Таҗетдин Ялчыгол исеме торырга тиештер, минемчә. Бу күренекле шәхеснең тууына узган елның октябрь аенда 250 ел, кайбер мәгълүматларга караганда 255 ел тулды. Узган елның 26 июнендә вафатына 180 ел булды.

Таҗетдин Ялчыгол – халкыбыз тарихының катлаулы чорында яшәгән әдип; татар, гарәп, фарсы, госманлы. төрек телләре белгече, шәрык гыйлемен, мәдәниятен өйрәнгән галим, педагог; табиб; дин әһеле, тарих, әдәбият, фәлсәфә,



*Җиденче Ялчыгол укуларында катнашучылар. Зәй районы Имәнлебаш авылы. 2019 ел*

медицина, хокук, илаһият китаплары авторы. Күпкырлы талант иясе 70 еллык гомеренең өчтән ике өлешен безнең Зәй елгасы буенда үткәрә. 1792–1799 елларда Каенлы авылында яшәсә, 1799–1824 елларда Кызыл Чапчак авылында гомер итә. Димәк, гомеренең 32 елын, иң гайрәтле чорын Каенлы һәм Кызыл Чапчакта яшәгән. Шуңа күрә татарның бу мәгълүм шәхесен без хаклы рәвештә үзебезнең якташыбыз дип исәплибез.

Конференция балаларга, оныкларга нәсыйхәт, авыл тарихына багышланган әдәби-музыкаль композиция белән башланып китте. Разия Якупова, күңел кылларын тибрәтерлек итеп, халык көенә сүзләрен Нәкый Исәнбәт язган «Туган ил» җырын башкарды, Рәйсә Абдуллина белән Резедә Гарипова мөнәҗәтләр әйттеләр.

Кызганыч, Т.Ялчыголның Каенлы чоры турында истәлекләр бик аз сакланган. Шулай булса да, без конференциядә катнашучыларга бу олуг шәхес турында мөмкин кадәр тулырак мәгълүмат бирергә тырыштык. Таҗетдин Ялчыголның тәрҗемәи хәле белән урта мәктәпнең тарих укытучысы Расим Фаиз улы Гарипов тырышты, «Каенлы һәм Кызыл Чапчак авыллары тарихларында Таҗетдин Ялчыголның урыны» дигән темага татар теле һәм әдәбияты укытучысы Лилия Рәүф кызы Гарипова, иҗаты турында китапханәче Гөлнар Фәрхетдинова, «Рухи пакьлеккә өндәгән «Рисаләи Газизә» ядкяре» темасына авыл мәчетендә дин һәм гарәп теле дәресләре алып баручы Әлфия Фәрит кызы Сәхәбиева чыгышлар ясадылар. Рөстәм Галиуллинның «Васыять» китабы – Таҗетдин Ялчыголга багышланган тарихи роман – турында да сөйләп үтелде. Романның утыз битендә (165–195 битләр) аның Татар Җиреклесендә (Каенлыда) яшәгән чоры сурәтләнә.

Әлеге чарада Зәй шәһәреннән килгән кунак, Таҗетдин Ялчыголның җиденче буын оныгы Гамир Госман улы Таҗетдинов та катнашты. Ул Ялчыгол нәселе дәвамчылары турында сөйләде һәм чыгыш ясаучыларга өстәп, күренекле бабасы турында кызыклы мәгълүматлар җиткерде.

Авыл китапханәсе әзерләгән бу фәнни-гамәли конференциядә Түбән Кама шәһәре Аксакаллар шурасыннан һәм «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасыннан килгән кунаклар, урта мәктәп укучылары, авыл халкы катнашты. Авыл имамы Нияз хәзрәт килгән кунакларга, бу чараны оештыручыларга зур рәхмәтен җиткерде. ■

*В каждом районе нашей республики есть имена, составляющие его гордость и славу. В Каенлинской сельской библиотеке Нижнекамской ЦБС состоялось очередное заседание из цикла «Их имена украшают историю родного края». На этот раз научно-практическая конференция была посвящена выдающемуся религиозному деятелю, народному целителю, писателю и просветителю Таджетдину Ялчыголу.*

• МӘШҺҮР КИТАПХАНӘЧЕЛӘР
• ЗНАМЕНИТЫЕ БИБЛИОТЕКАРИ

*Ольга ИВАНОВА,*
*писатель*

# Великие библиотекари: Иван Крылов

АВТОР знаменитых басен Иван Андреевич Крылов известен нам с детских лет. У кого в памяти не остался портрет тучного, добродушного дяденьки с пышной седой шевелюрой, красующегося на страницах школьного учебника? А вместе с воспоминанием приходят на ум летучие, незабываемые, лёгкие для запоминания строки: «Вороне где-то Бог послал кусочек сыра» или «Ай, Моська! знать она сильна, что лает на Слона!» И кому известна другая, не менее значимая сторона деятельности баснописца – его трудоёмкая, долгая и самозабвенная работа библиотекарем?

Иван Андреевич получил предложение служить в готовящейся к открытию Императорской Публичной библиотеке Санкт-Петербурга накануне своего 43-летия, в январе 1812 года. К тому времени он уже устал от беспорядочной жизни старого холостяка, не имевшего привязанности к одному месту и любимому делу. Конечно, любимое дело у Крылова имелось, сказывалось его страстное увлечение литературой, потому стезя поэта, прозаика, драматурга и издателя сатирических журналов пролегала через всю его жизнь с ранних лет.



*Иван Крылов.* Художник Иван Эггинк

Но особо преуспеть удалось в сочинении басен, где его острый, иронический, всё подмечающий ум сумел блеснуть во всей своей мощи. Будучи страстным игроком в карты, Иван Андреевич исколесил многие губернии России, меняя квартиры и места жительства, но с возрастом стал понимать, как тяжёл подобный образ существования и решился осесть в столице. Петербург не преминул встретить баснописца с почётом. В декабре 1811 года Крылова избрали членом Российской Академии, а за признанием заслуг поступило и судьбоносное предложение от Оленина.

С директором Императорской Публичной библиотеки Алексеем Николаевичем Олениным его связывало давнее знакомство, переросшее в дружбу. Оленин ценил Крылова за искромётный талант, за уже вполне состоявшийся на литературном поприще авторитет и за связи в среде книготорговцев, что, безусловно, могло пригодиться в новой деятельности баснописца. Алексей Николаевич взял на себя заботы о благоустройстве Ивана Андреевича в Петербурге и выпросил для него у государя пожизненный годовой пансион в 1 500 рублей, заметно умножившийся впоследствии. Государственное содержание позволило несколько упорядочить жизнь вечного скитальца и позабыть о нужде, сопровождавшей Крылова с детства.

Службу в Публичке Иван Андреевич начал на пару с известным библиографом Василием Степановичем Сопиковым в Русском отделении, поначалу насчитывающем всего четыре книги. У кого-то и руки могли опуститься, но директор недаром набирал в библиотеку людей упорных, настойчивых и трудолюбивых. Итак, дело в Рус-

ском отделе закипело. Ещё в 1810 году М. М. Сперанский на основе доклада Оленина составил «Положение об управлении Императорской Публичной библиотекой». По сути это был первый библиотечный законодательный акт России, и в нём содержался особо важный пункт об обязательном экземпляре. По нему каждое издаваемое в стране печатное издание безвозмездно доставлялось в библиотеку в двух экземплярах. За год это составляло от 300 до 600 штук, не считая дублетов.

Начиная с 1811 года, обязательные издания стали пополнять фонд русского отделения, но куда более заметное поступление происходило благодаря стараниям Крылова. Знакомые книгопродавцы уступали Ивану Андреевичу за полцены, а то и просто дарили тома отечественных поэтов и прозаиков, переводные труды зарубежных авторов и подшивки журналов. Ассигнование на подобные нужды казной не предусматривалось, и средства приходилось выбивать. Кто из сослуживцев имел такую возможность, использовал связи и влиятельные знакомства; другие обращались с бесконечными просьбами к высоким чиновникам, обивали пороги учреждений. За библиотечное дело коллеги радели, словно за своё собственное, и каждую добытую книгу несли в сокровищницу знаний почётным трофеем. До намеченного на 1812 год открытия заведения оставалось немного времени, как вдруг грянула война, и самую ценную часть библиотеки срочно эвакуировали из города в Олонецкую губернию, вернув лишь после изгнания Наполеона из России.

Такова была хлопотная судьба книжных фондов, но надо заметить, что и сама библиотека имела долгую и трудную историю, начавшуюся с задумок просвещённой Екатерины II. Императрица обратила внимание на недостающий России источник народного просвещения – такой, как открытые для всех книгохранилища или публичные библиотеки. Высочайший взор на нужды культуры государыня направила уже в конце жизненного пути, хотя о библиотеке заговаривали ещё в начале её царствования. В 1795 году утвердили архитекторский проект Егора Соколова и назначили место для будущего здания на пересечении улицы Сенной и Невского проспекта. Императрица даровала новому детищу телескоп для будущей обсерватории, которую следовало пристроить к зданию библиотеки, личные собрания Вольтера и Дидро, рукописные и книжные коллекции братьев Залуских и собрания Эрмитажной библиотеки. Последнее распоряжение по поводу отпуска средств на постройку здания Екатерина Великая сделала за месяц до своей кончины. Павла I проект матушки волновал мало, но, к счастью, нашёлся неравнодушный меценат, граф Строганов, продолживший начатое дело. Александр Сергеевич Строганов так же взял на себя заботу о пополнении фондов коллекциями, находящимися за рубежом. Он убедил в такой необходимости следующего российского императора Александра Павловича, на правление которого пришлось открытие Публички.

Императорскую Публичную библиотеку торжественно открыли в январе 1814 года, приурочив начало работы к первому посещению заведения государем. Красивое здание с колоннами, статуями и величественными залами впечатляло каждого. Но главным являлось не само строение, а его содержимое – бесценный фонд книжных, печатных и рукописных изданий. Алексей Николаевич Оленин писал в том же году: «Истинная цель открытого книгохранилища состоит в том, чтоб всякий, кто бы он ни был, мог требовать для своего употребления всякого рода печатные книги, даже самые редкие <…> и пользоваться ими безвозмездно, не унося их токмо домой». На открытие присутствовало двести гостей, звучали пылкие речи, стихи и добрые пожелания, которым внимали преданные сотрудники библиотеки, и в их числе Иван Андреевич Крылов, с готовностью поучаствовавший в действие и прочитавший сочинённую по этому случаю басню «Водолазы»:

Какой-то древний царь впал в страшное сомненье:

**Не более ль вреда,**
**чем пользы, от наук?**
**Не расслабляет ли**
**сердец и рук ученье?**
**И не разумнее ль поступит он,**
**Когда учёных всех**
**из царства вышлет вон?**

Читал Крылов превосходно, легко и естественно, все персонажи разговаривали у него по-особому, и слушатели получали двойное удовольствие, как от замечательного текста, так и от таланта чтеца.

Минули торжества, и потекли библиотечные будни, где три раза в неделю – среду, четверг и пятницу Публичка открывалась для читателей. Русское отделение занимало почти весь первый этаж библиотеки, который выходил окнами на Александринскую площадь (ныне площадь Островского) и на Невский проспект. Дежурный библиотекарь, а им был либо Сопиков, либо Крылов, принимал заказы, приносил книги и следил за их сохранностью и порядком в круглой зале нижнего этажа, украшенной мраморными статуями и бюстами писателей и учёных. Здесь размещался читальный зал с его непередаваемой атмосферой, музейной тишиной, прерываемой лишь шелестом страниц и осторожным покашливанием простуженного читателя. Остальные дни недели предназначались для разбора книг, каталогизации и других работ, которые Иван Андреевич любил, несмотря на их внешние громоздкость и монотонность.

Вместе с коллегой В. С. Сопиковым Крылов составил первый каталог своего отделения – «Каталог Российским книгам в Императорской Публичной библиотеке находящимся». Огромный рукописный фолиант сохранился до нашего времени и в него вошли сведения о 2 100 книгах. Над каталогом Иван Андреевич работал около 10 лет и заканчивал его уже без Сопикова, покинувшего свой пост в 1816 году сначала по причине болезни, а потом – и смерти. Одновременно составлялись два тома систематического каталога, законченных Крыловым тремя годами позже. Составлению систематического каталога, предназначенного исключительно для работников библиотеки, предшествовала большая и кропотливая работа. Иван Андреевич подошёл к стоящим проблемам с присущей ему продуманностью и определил основную задачу – возможность быстрого поиска требуемой книги, как в каталоге, так и на полке в шкафу. Одним из его усовершенствований стало создание нумерационной тетради – своеобразный инвентарь или топографический каталог. В ней впервые в истории библиотечного дела России Крылов указывал, как он говорил, «приметы книги», а иначе шифр. На книге и в каталоге ставились две цифры: ими обозначались место на полке и номер самой полки. На некоторых книгах и сейчас сохранились цифры, поставленные рукой Ивана Андреевича. Позже, в 40-е годы XIX века, библиотека окончательно пошла по пути, указанному И. А. Крыловым, когда расстановку книг и каталогов связали шифром, поместив его и на книге, и на карточке.

Но основным делом библиотекаря Крылова оставалось пополнение книжного фонда. Хотя был установлен обязательный экземпляр всех печатавшихся книг, но не всегда Публичка его получала. Иван Андреевич брался за дело с завидной энергией, требуя неукоснительного соблюдения указа. Попутно он обходил издателей и книготорговцев, знакомился с частными коллекциями в поисках редких книг или недостающих изданий. Сохранились многочисленные докладные записки и рапорты Ивана Андреевича, говорящие как широки были его поиски и сколь различные области интересовали нашего библиотекаря – книги по истории, географии, физике, медицине, астрономии, сельскому хозяйству, домоводству и, конечно, художественная литература. В феврале 1829 года в одной из таких записок Крылов писал: «Санкт-петербургский книгопродавец Александр Смирдин по приложенному реестру представил в императорскую Публичную библиотеку для покупки разного звания книг, вышедших из печати до 1811 года, ценою до 5 000 рублей, а так как оных книг в Библиотеке не находится, то я, полагая нужным таковое приумножение и находя очень выгодным для Библиотеки, — имею честь представить всё сие на благоусмотрение вашего превосходительства».

Иван Андреевич развивал поистине бурную деятельность, когда дело касалось редких и ценных книг. Так было с приобретением части собрания старопечатных книг и рукописей графа Ф. А. Толстого. Следовало найти огромную сумму в 150 000 рублей для того, чтобы эта сокровищница стала частью Публичной библиотеки, и купить коллекцию удалось, но при сверке одной книги, указанной в описи, не оказалось на месте. Крылов повёл долгие переговоры с графом, и так как книга нигде не обнаружилась, настоял на замене.

Немало потрудился Иван Андреевич над улучшением библиотечного дела. Даже мелочи не обходил стороной, так, например, завёл особые футляры в виде книг для небольших брошюр, заботясь об их сохранности и лучшем поиске. О его трепетном отношении к книге рассказывал современник и друг Крылова П. А. Плетнёв. Как-то Иван Андреевич выпросил у Оленина на дом роскошную библиотечную книгу о Египте с замечательными гравюрами. Рассматривая фолиант, он по своей неаккуратности опрокинул на книгу чашку с кофе. Крылов схватил ушат с водой и принялся поливать книгу. Увидев такое безобразие, служанка бросилась к жившему этажом выше библиотекарю и поэту Н. И. Гнедичу, крича, что её барин не в своём уме. Но Иван Андреевич объяснил поражённому Гнедичу, что без воды не было никакого способа свести с листков пятен. Так и оказалось. Когда книгу просушили, на ней осталась лишь одна жёлтенькая полоска по краю страниц.

В Русском отделении у библиотекаря Крылова царил порядок в отличие от служебной квартиры, находящейся в соседнем особняке. Квартира досталась Ивану Андреевичу от Василия Степановича Сопикова. Когда старший коллега вышел в отставку, Крылов наследовал его должность и жильё. Квартира состояла из трёх помещений, окна выходили на Гостиный двор. Баснописец облюбовал последнюю из комнат, угловую, где за перегородкой стояла кровать, а в светлой половине, у окон, Иван Андреевич обычно отдыхал на диване. У него не было оборудованного кабинета и письменного стола с обязательными атрибутами человека пишущего, красивой мебели, ковров и прочих вещей, призванных создавать комфорт. Единственным украшением полупустого зала являлся большой портрет, где профессор Академии художеств Р. М. Волков изобразил Ивана Андреевича в его любимом халате. Но даже в зале, где принимались посетители, в глаза бросались не ухоженность, скудость мебели, на всём лежал толстый слой пыли, пепел от любимых хозяином сигар с мундштуком,

голубиный помёт. Форточки, а то и окна в квартире всё лето держались распахнутыми, а на подоконнике специально рассыпалось зерно для кормления пернатых друзей, которые беспрепятственно расхаживали по комнатам. Редко кто решался сесть на стул, не очистив его прежде или обмахнув носовым платком.

Крылова подобные мелочи мало беспокоили, как и собственный внешний вид – неряшливый и вечно растрёпанный. В обыденной жизни он отличался спокойствием и беспечностью, и только две вещи занимали и радовали его – занятие литературой и еда. О чревоугодии Ивана Андреевича ходили анекдоты, но не все знали, что его непревзойдённый аппетит являлся следствием голода, перенесённого мальчиком Ваней в осаждённом Оренбурге, и бесконечной нужды, которую Крылов терпел многие годы. А анекдотов было не счесть, и баснописец сам поддерживал славу обжоры, неряхи и ленивца. Поговаривали, собираясь на маскарад, он спрашивал совета, что ему надеть у жены и дочери Оленина, а те отвечали, что достаточно вымыться и причесаться, чтобы стать неузнанным. В Английском клубе, не обойдя вниманием ни одного блюда и наевшись до отвала, он обычно вставал и, перекрестившись, произносил: «Много ли надо человеку?» Сотрапезники, являвшиеся свидетелями, сколько надобно Крылову, принимались хохотать. А Иван Андреевич, вполне довольный собой, удалялся по другим делам.

Большой отрезок жизни, проведённый баснописцем в библиотеке, ознаменовался подъёмом творческой деятельности. Оленин всячески поощрял у своих подчинённых занятия литературой, а Крылову легко сочинялось в царстве книг. Хотя сюжеты брались у полюбившегося ещё в детстве Лафонтена, образы героев Иван Андреевич списывал с сотрудников Публички или с тех людей, с кем сталкивала долгая жизнь. Сто пятьдесят три басни из двухсот пяти Крылов написал в эти годы.

Старость подкралась незаметно, он успел сделать для библиотеки несравнимо много, и часто, после отставки Сопикова, тянул воз Русского отделения в одиночку. Лишь иногда появлялись у него помощники, а среди них знаменитые Антон Антонович Дельвиг, Михаил Николаевич Загоскин и книговед Иван Павлович Быстров. Один из коллег Крылова В. И. Собольщиков так описывал его рабочий день в последние месяцы: «Придя дежурить после обеда, он (Крылов) ложился обыкновенно на диван и читал лёжа. А когда являлись посетители, то он, не вставая, указывал им на шкап и приготовленные для них книги и просил брать, что кому нужно. Частенько он засыпал на своём диване, и покровительствовавший ему Оленин в таких случаях говаривал окружающим: «Вероятно, Иван Андреевич нездоров»».

Сам государь любил баснописца, в почтенном возрасте награждал чинами и повышением пансиона, казалось, можно и отдохнуть, но Крылов продолжал трудиться в библиотеке и часто говорил: «Я вот уже так здесь привык, что почитаю для себя забавою, игрушкою наклеивать да переклеивать буквы на книгах; что другому покажется тяжело. Я своей должности ни на какую не променяю; дело совсем другое, если бы я был моложе». Всем своим деятельным существованием, бескорыстным служением библиотечному делу он только подтверждал мораль одной из своих басен «Орёл и пчела»:

**Но сколь и тот почтен,**
**кто в низости сокрытой,**
**За все труды,**
**за весь потерянный покой,**
**Ни славою, ни почестьми**
**не льстится,**
**И мыслью оживлен одной,**
**Что к пользе общей он трудится.**

Библиотеке И. А. Крылов отдал 29 лет и вышел в отставку в 1841 году, когда ему было за 70. Спустя ещё три года, 9 ноября 1844 года, Иван Андреевич скончался. Похоронили его в Александро-Невской лавре, а 12 мая 1855 в Летнем саду Петербурга открыли памятник Крылову работы П. К. Клодта. Он стал первым памятником баснописцу в столице, но не менее значимым монументом остаются труды Ивана Андреевича на благо библиотеки и всего библиотечного дела. Деятельность И. А. Крылова способствовала превращению со временем Императорской Публичной библиотеки в одно из крупнейших книгохранилищ мира – Российскую национальную библиотеку. Исследования Крылова в библиотечном деле трудно переоценить, они выдержали поверку временем и применяются до сих пор. ■

*Иван Андреевич Крылов исеме безгә бала чагыбыздан ук оста мәсәлче буларак билгеле. Әмма аның Император җәмгать китапханәсендә китапханәче булып эшләгәнен күпләр белмидер дә. Әлеге китапханә башлангыч чорында күп авырлыклар кичергән. Китапханәче И.А.Крыловның төп вазифасы китап фондын тулыландыру булса да, ул китапханәчелек эшен үстерү белән дә шөгыльләнгән. Хезмәттәше В.С.Сопиков белән бергә алар Рус бүлекчәсенең беренче каталогын төзегәннәр. И.А. Крылов – үзенең 29 ел гомерен Җәмәгать китапханәсенә хезмәт итүгә багышлаган шәхес. Эшчәнлегенең җимешләре белән хәзерге заман китапханәчеләре дә һаман файдалана әле.*

*Гөлнирә ХӨСӘЕНОВА,*
*Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге хезмәткәре*

# Татар журналисты Шәриф Байчура

1997 елда Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә 527 китап һәм архив документыннан торган Үзбәк Байчура тупланмасы төзелде. Аның хронологик чикләре 1879–1996 еллар арасына туры килә. Бу коллекциянең нигезен тел гыйлеме, телләр тарихы, тюркология, алтаистикага караган хезмәтләр, фин-угор һәм төрки телләр буенча сүзлекләр тәшкил итсә, калган өлешен тел галиме Үзбәк Байчура һәм аның әти-әнисе – Шәриф Байчура белән Әминә Алимбәккә кагылышлы архив материаллары алып тора. Әлеге мәкалә югарыда телгә алынган өч шәхеснең берсе – Шәриф Байчураның тормыш юлы, эшчәнлеге һәм коллекциядәге аңа бәйләнеше булган документлар турында булыр.

Кызганычка каршы, кайвакыт тарих китапларында язылган мәгълүматлар дөреслек белән тәңгәл килми. Ә Шәриф Байчураның архив документлары белән танышкан укучының аңында ватаныбыз тарихына карата үз күзаллавы формалаша. Әлбәттә, журналист үз мәкаләләрендә тарихи вакыйгаларны фәкать коммунистик караштан гына чыгып бәяли. Тик коллекцияне җентекләп өйрәнгән кеше Байчуриннар гаиләсе яшәгән чорга карата башка төрле нәтиҗәләр дә ясарга мөмкин.


*Шәриф Байчура*

Шәрифулла Хөсәен улы Байчура – XX гасырда татар матбугатына үз өлешен керткән журналист, тәнкыйди мәкаләләр авторы, җәмәгать эшлеклесе. Ул 1892 елның 1 сентябрендә Буа төбәгенең Ташкичү авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә (соңрак Бәбки авылына күченәләр). Шәрифнең әтисе Хөсәен абзый тормыш итү, мал табу ягыннан бик әрсез кеше булмаса да, балаларына аң-белем бирүгә зур көч куя. Шәриф Байчура үзенең истәлекләр дәфтәрендә болай дип яза: «Безнең балалар – сеңелләр һәм, шул исәптән, мин дә – уку-язуга бик тиз өйрәнеп китә идек. Алты-җиде яшьтә инде өйдә булган төрки китапларны иркен укыйбыз. Шулай ук, язарга да тиз өйрәнелә. Авылыбызда укый-яза белүче кешеләр бик сирәк очрагանга, безгә еш кына хат укытырга, хат яздырырга киләләр. Шул сәбәпле миңа, балаларның олысына, укый-яза белмәү бөтенләй оят бер эш кебек тоела иде».

14 яшенә кадәр Дәвеш мәдрәсәсендә (Бәбки авылыннан 5 чакрым ераклыкта) гыйлем алган Шәриф Казанда уку теләге белән янып йөри башлый. Тик матди яктан шактый авыр яшәгән гаиләнең улларын Казан мәдрәсәсендә укытырга хәлләреннән килми. Шуңа да карамастан, әнисе: «Ачкыч бавымдагы (хәситәдәге) көмеш тәңкәләр һәм башка шара-бараларны сатарбыз, улыбызны ничек тә булса үзе теләгәнчә укытыйк инде», – дип, Хөсәен абзыйны күндерә. Әти кеше, баласы шәһәргә китеп, башка милләт кешеләре йогынтысында телен, динен онытыр дип бик курыкса да, Шәрифнең: «Бу хәл беркайчан

да булмаячак», – дигән вәгъдәсен ишеткәч, ризалаша. Шулай итеп, дөньяви фәннәрдән артта булган, әмма гарәп телен бик яхшы белгән үсмер Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте булып китә.

Казан мәдрәсәсендә укый башлагач, Шәриф Байчураның уку системасына, дингә, сәясәткә, дөньяга карашы төптән үзгәрә. Ул «Мөхәммәдия»нең башка мәдрәсәләргә караганда алдынгы булуын таныса да, бу уку йортында күбрәк дини дәресләргә, гарәп теленә генә өстенлек бирелүе, рус теленең уку программасында бөтенләй булмавы белән килешеп бетми. Егет, беренче елын уңышлы гына тәмамлаганнан соң, алга таба бу уку йортында белем алырга теләмәвен аңлап, мәдрәсәне ташлый. Аның яңа хыялы – Татар укытучылар мәктәбенә укырга кереп, земство тарафыннан ачылган мәктәпләр өчен рус теле укытучысы һөнәре алып чыгу була. Тик әнисенең кисәк кенә тиф чиреннән үлеп китүе һәм кечкенә сеңелләренең ятим калулары сәбәпле, Шәриф бу имтиханнарга әзерләнә алмый. Ләкин кире авылга әйләнеп кайтмый – ул рус телен яхшы белгән яшьләр белән таныша, гаиләле студентка фатирга кереп, кичен аннан рус теле дәресләре ала, үзе дә кайбер зыялыларга гарәп теленнән дәресләр бирә.

Акрынлап Шәриф Байчура үзен журналистика өлкәсендә сынап карый башлый. Егет ул заман өчен «иске фикерле» саналган «Бәянелхак» типографиясенә эшкә урнаша, ә мәкаләләре «Кояш» газетасында, «Сөембикә», «Русия сәүдәсе» кебек журналларда басылып чыга. Өстәвенә, кайбер танылган рус язучыларының әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә.

Яшь журналист Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Кәрим Тинчурин, Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов кебек танылган шәхесләр белән аралаша, аларның хөр



*Әминә Алимбәк*

фикерле, гыйлемле булуларына соклана. Коллекциядә Шәриф Байчураның әлеге шәхесләр белән бәйле танышу тарихлары, истәлекләре дә саклана. Болар татар әдәбиятын яратучылар өчен бик зур табыш булып тора.

1921 елда Шәриф Байчура үзе кебек коммунизм төзү идеясе белән янып йөргән студент кыз – Әминә Алимбәккә өйләнә (Әминә Алимбәк – татар хатын-кызлары арасында беренче акушер-гинеколог). Ә ике елдан соң уллары Үзбәк туа. Тик бу гаиләнең гомере шактый кыска булып чыга – кечкенә Үзбәкне ире тәрбиясендә калдырып, Әминә үзен тулысы белән җәмәгать эшләренә һәм медицинага багышлый. Безнең күзлектән караганда, әни кешенең бу адымы аңлашылып та бетми кебек. Тик ул чорда коммунизм «тудырачак» матур киләчәккә өметләнгән яшьләр арасында мондый очраклар аз булмый. Шулай итеп, киләчәктә тел галиме буларак танылачак Үзбәк Байчура фәкать этисенең тәрбиясендә үсә.

Октябрь инкыйлабы, Гражданнар сугышы һәм колхозлашу елларында Шәриф Байчураның эшчәнлеге киңәя. Журналист шушы елларда агитацион рухтагы күпсанлы мәкаләләр яза. Кайбер мәкаләләре «Кызыл солдат» псевдонимы белән басылып чыга. Шулай ук ул, колхозлашу еллары башлангач, авылларга чыгып, халыкны колхоз төзергә өндәп йөрүдә дә катнаша.

Коллекциядә Шәриф Байчураның туган, үскән авыллары Ташкичү һәм Бәбки хакында тарихи мәгълүматлар саклана. Бу материаллардан күренгәнчә, Бәбки авы-



*Шәриф Байчура архивы материаллары*

лында бергә яшәгән руслар белән татарлар бер-берсенең гореф-гадәтләрен, йолаларын хөрмәт иткәнәр. Бу материаллар укучыга инкыйлаб алды елларын, шул чордагы татар халкы тарихын, башка халыклар белән булган мөнәсәбәтләрен күзалларга ярдәм итә.

Шәриф Байчураның коллекциядә сакланучы материалларын берничә төркемгә бүләргә мөмкин:

1. Туган-үскән авыллар һәм нәсел тарихы.

2. Татар әдәби теленә карата тәнкыйть мәкаләләре һәм тәрҗемәләр.

3. Инкыйлаб, Гражданнар сугышы, колхозлаштыру темасына язылган мәкаләләр.

4. Танылган шәхесләр һәм революционерлар хакында язылган мәкаләләр (И.Сталин, В.Ленин, М.Вахитов, Н.Тюрякулов, К.Хәйруллин).

5. XX гасыр башында иҗат иткән шагыйрьләр, язучылар, драматурглар, җәмәгать эшлеклеләре турында хатирәләр (Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил, Фатих Әмирхан, Һади Такташ һ.б.).

6. XX йөз башында татар яшьләре хәрәкәтенә карата язылган тарихи мәкаләләр.

Алда әйтеп үткәнчә, Шәриф Байчура Совет хакимияте урнаштыру, колхозлаштыру эшләрендә актив катнашып йөрсә дә, дәүләт тарафыннан «халык дошманы» булуда гаепләнеп, ике тапкыр партиядән чыгарыла. 1933 елда булган репрессиясенең сәбәбе – «Татиздат» җитәкчеләренең «намуссыз» гамәлләренә «игътибарсызлык күрсәтү»дә булса, икенчесендә – Сталин сәясәтен тиешенчә хөрмәт итеп бетермәү белән аңлатыла.

Репрессия корбаны булу сәбәпле, Шәриф Байчура бик озак еллар эшкә урнаша алмый интегә. Яшьли ятим калган нәни сеңелләре үсеп җитеп, аңа тормышының иң авыр минутларында ярдәмче булалар. Ә Хәдичә Байчурова дигән сеңлесе авыл хуҗалыгы өлкәсенә керткән фәнни казанышлары өчен СССРның Дәүләт премиясе белән бүләкләнә. Шәриф Байчураның бертуганнары аңа матди яктан да, ятим калган Үзбәкне тәрбияләүдә дә бик булышалар.



*Шәриф белән Үзбәк Байчуралар*

Ш.Х. Байчура 1972 елда вафат була.

Гомерен җәмәгать эшләренә, матбугатка һәм улын тәрбияләүгә багышлаган бу журналист хакында бик күп язарга булыр иде. Шәриф Байчура – танылган шагыйрь дә, язучы да, галим дә түгел. Әмма ул – без бүген хөрмәтле торган замандашлары белән тыгыз мөнәсәбәттә торган, алар белән янәшә атлап, бер үк төрле уй-хыяллар, өметләр белән яшәгән шәхес. Шул сәбәпле, журналистның язып калдырган истәлекләре, документлары киләсе буыннар өчен кызыклы ачыш һәм файдалы мирас булып тора. ■

*В фондах Национальной библиотеке Республики Татарстан наряду с книжной коллекцией учёного-лингвиста Узбека Байчуры хранится и семейный архив Байчуриных. Часть архива состоит из воспоминаний и документов, принадлежавших отцу учёного – татарскому журналисту Шарифу Байчуре.*

*Байчура Шариф Хусаинович внёс немалую лепту в развитие татарской журналистики первой половины XX века. Он является автором статей о татарских общественных деятелях.*

*Родился он в деревне Ташкичу (в настоящее время – Буинский район РТ), в семье муллы. Грамоте и письму его обучал отец. Позже он учился в Казанском медресе «Мухаммадия».*

*Ш. Байчура начинает свою журналистскую деятельность в известных татарских газетах и журналах начала XX века, знакомится с видными деятелями того периода, как Габдулла Тукай, Фатих Амирхан, Карим Тинчурин, Галиасгар Камал, Галимджан Ибрагимов.*

*Он с радостью встречает революцию и в своих статьях начинает вести агитационную работу. Однако, позже он был исключён из партии и долго не мог найти работу.*

*Его женой была Амина Алимбек, ставшая первой из татарских женщин врачом-акушером. Судьбе было угодно, чтобы они расстались и Шариф Байчура один воспитывал их общего сына, будущего учёного-лингвиста – Узбека Байчуру.*

*Ш. Х. Байчура ушёл из жизни в 1972 году.*

# О библиотеках Татарстана в периодической печати

# Татарстан китапханәләре хакында вакытлы матбугат

**_Светлана МИҢНЕХАНОВА,_**
_ТР Милли китапханәсе татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү бүлегенең библиография секторы мөдире_

- Иванычева О. Как библиотекам выжить и процветать в век цифровых технологий?: [в каком направлении должно развиваться библиотечное дело в век цифровых технологий? Эти вопросы обсуждались на ежегодном совещании директоров республиканских и муниципальных библиотек Татарстана] // Казанские ведомости. – 2019. – 17 апр. – С. 1.
- Трифонова П. Место, куда можно прийти по любому поводу: [в Казани состоялось ежегодное совещание директоров республиканских и муниципальных библиотек Татарстана] // Республика Татарстан. – 2019. – 26 апр.
- Китапханәләр турында кызыклы фактлар: [китапханәләр тарихы] // Шәһри Чаллы. – 2019. – 29 май. – Б. 4.

## Милли китапханә хакында
## О Национальной библиотеке

- Гарифуллина Ч. «Без язачакбыз, язарга хаклыбыз!»: [ТР Милли китапханәсендә «Ел китабы–2017» бәйгесе йомгакларына багышланган тантана тур.] // Ватаным Татарстан. – 2019. – 17 апр. – Б. 4.
- Мөхәммәтова Р. «Ел китабы–2017» бәйгесенә нәтиҗә ясалды: [2017 елда дөнья күргән һәм 2018 елда Республика китапханәләрендә иң күп укылган китаплар авторларын ТР Милли китапханәсендә котладылар] // Атна вакыйгалары. – 2019. – 19-25 апр. – Б. 10.
- Шәрапова Й. Укыйлар икән бит: [ТР Милли китапханәсендә республикада ел саен үткәрелеп килә торган «Ел китабы» конкурсы җиңүчеләрен котладылар] // Шәһри Казан. – 2019. – 19 апр. – Б. 7.
- Мөбарәкшина Р. Төнлә – китапханәгә: [ТР Милли китапханәсендә сигезенче тапкыр «Китапханә төне» узды] // Ватаным Татарстан. – 2019. – 24 апр. – Б. 4.
- Кашапова С. Китапханәдә Коръән тупланмасы: [ТР Милли китапханәсенең Күргәзмәләр залында «Коръән нуры» күргәзмәсенең ачылышы] // Мәдәни җомга. – 2019. – 26 апр. – Б. 18.
- Рәхим Г. Китап – хәзинә: [туган тел, китап язмышы, «Ел китабы» конкурсы тур. ] // Ватаным Татарстан. – 2019. – 14 май. – Б. 5.
- Татарстан Республикасының Милли китапханәсе // Безнең мирас. – 2017. №10. – Б. 100-107; №11. – Б. 104-109; №12. – Б.108-113; 2018. – №1. – Б. 106-109; №2. – Б. 104-107; №4. – Б. 104-108; №5. – Б. 106-109; №6. – Б. 100-103; №7. – Б. 106-109; №8. – Б. 104-107; №9. – Б. 102-107; №10. – Б. 106-111; №11. – Б. 106-111; №12. – Б. 98-103; 2019. – №1. – Б. 104-109; №2. – Б. 110-113; №3. – Б. 112-113; №4. – Б. 108-109; №5. – Б. 112-113; № 6. – Б. 112-115.
- Арсланова Ф. Ялчыгол кабат кайтты: [«Җыен» фонды «Шәхесләребез» сериясендә бастырып чыгарган «Таҗетдин Ялчыгол» дигән яңа китапны тәкъдим итү кичәсе ТР Милли китапханәсендә узды] // Ватаным Татарстан. – 2019. – 28 май. – Б. 2.
- Сафиуллина Р. Мәдәни «супермаркет»тан мәдәни «гипермаркет»ны ничек ясарга?: [ТР Милли китапханәсе тур.] // Идел. – 2019. – № 5. – Б. 77.
- Кашапова С. Катлаулы язмыш иясе: [ТР Милли китапханәсендә «Таҗетдин Ялчыгол» китабын

тәкъдим итү кичәсе] // Мәдәни җомга. – 2019. – 7 июнь. – Б. 15.

• Мөбарәкшина Р. Укы. Уйла. Сөйлә.: [ТР Милли китапханәсе Лобачевский бакчасында «Китапханә паркта» дигән мәдәни бәйрәм үткәрде] // Шәһри Казан. – 2019. – 11 июнь. – Б. 11.

• Шәрапова Й. Ялчыгол нәселендә аерылышучылар юк: [Милли китапханәдә «Тажетдин Ялчыгол» китабын тәкъдим итү кичәсе] // Шәһри Казан. – 2019. – 11 июнь. – Б. 7.

• Театр тарихы күргәзмәсе: [Милли китапханәнең сәнгать бүлеге Россиядә Театр елы кысаларында «Россиядә драма театры. Тарих һәм хәзерге заман» дип аталган күргәзмәләр циклы тәкъдим итә] // Мәдәни җомга. – 2019. – 12 июль. – Б. 4.

• Китапханә чемпионатка әзерләнә: [Милли китапханәнең Күргәзмәләр залында август ае дәвамында «Һөнәр сайлау – үз эшеңнең остасы булу» дигән күргәзмә эшли] // Мәдәни җомга. – 2019. – 9 август. – Б. 4.

* * *

• Президент поручил детально продумать функции нового здания Национальной библиотеки: [16 июля Р.Минниханов ознакомился с ходом реконструкции здания НКЦ «Казань» для размещения в нём Национальной библиотеки РТ] // События недели. – 2019. – 19-25 июля. – С. 8.

